www.madanizhomga.ru

# Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 41 (1457) 20 октябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

8-9

**Утыз елга якын гомерен «Мәдәни җомга» газетасына багышлаган Сөембикә Кашапова бүген Татарстанның иң абруйлы журналистларының берсе булып санала.**

12-13

**Моңа кадәр гаять сирәк кешеләргә генә билгеле булган Люция апа – Муса Җәлил кызын этисенең газиз ватаны булган Оренбург өлкәсенә алып баргач, һәммә халык аңа гашыйк булды.**

14-15

**Пенза өлкәсенең 12 мәчетле һәм 10 мең татар яши торган Урта Әләзән авылы үзенең төзеклеге, чисталыгы, матурлыгы гына түгел, хезмәт сөйгән халкы белән дә сокландыра.**

# Әткәсенең туган нигезенә Дога багышлады кызчыгы!..

## БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы «Зәкят» хәйрия фонды зыян күргән палестиналыларга гуманитар ярдәм җыю турында игълан итте.

- 2024 елда индексациядән соң ана капиталы беренче балага – 631 мең сум, икенче һәм аннан соңгы балага 834 мең сум тәшкил итәчәк.

- Россия хөкүмәте 1,5 яшькә кадәрге балалар тәрбияли торган эшләүче ата-аналарга ярдәм чаралары турындагы закон проектын хуплады.

- Татарстан Республикасында, Россиядә һәм чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызны берләштерә торган «Татарча диктант» Бөтендөнья акциясе узды.

- Минзәләнең С.Өметбаев исемендәге татар дәүләт драма театры Әнкара шәһәрендә «Этос» XV Халыкара театр фестивалендә Флорид Бүләковның «Сөясеңме, сөймисеңме» трагикомедиясен күрсәтте.

- Татарстан Республикасының Милли музеенда «Сания»: беренче татар операсы» күргәзмәсе ачылды.

- Самарада Идел буе халыкларының мәдәнияте һәм традицияләре дөньясына багышланган «Күңелсезләнмә» II этнографик фестивале узды.

- Татарстанда 61 археология һәйкәленә чикләр һәм территориядән файдалануның махсус режимы расланды.

- Кырым күпере тулысынча торгызылды һәм автомобиль хәрәкәте өчен ачык.

- Ел башыннан Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге белгечләре 34 баланы гаиләгә урнаштырган.

### БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

**20 октябрь** – дирижёр, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Әзһәр Хәниф улы Абдуллинның тууына 100 ел (1923-1993);

– ТАССРның атказанган артисты Асия Әхмәтша кызы Харисова (Разаутдинова)ның тууына 100 ел (1923-2011);

– рәссам, график, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге премиясе лауреаты Булат Шаһинур улы Мәрдановның тууына 70 ел (1953-2012).

**26 октябрь** – актёр, режиссёр Камал I нең (Габдулла Галиәкбәр улы Камалетдиновның) тууына 130 ел (1893-1933);

– ТАССРның атказанган артисты Вәли Галкинның тууына 110 ел (1913-1996);

– скрипкачы, педагог, профессор, ТАССРның атказанган артисты, халыкара конкурслар лауреаты Зариус Госман кызы Шаһморзаеваның тууына 90 ел (1933-2010).

### СЫНАМЫШЛАР

● Күз озын килсә, яз соң килер.

● Суганның кабыгы ике кат булган елны кыш җылы килер, ә кабыгы күп катлы икән - кыш салкын булыр.

● Октябрь аенда кояш тотылса, киләсе апрель-майда яңгыр яумас.

● Агач яфракны соң койса, ел авыр килә.

### КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 24 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 34 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 10 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **27 октябрьдә 9 сәгать 39 минут** тәшкил итәчәк.

### СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(22-29 октябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

### ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

**Бүген рабигүл ахир аеның 5 нче көне**

**КӨН КАДАГЫНА**

Эльмира СИРАҖИ

# Казанның Җәмигъ мәчетенә – татар йөзе!

Казанда «Диалоглар» архитектура-шәһәр төзелеше конференциясе кысаларында «Заманча гыйбадәт йортларын проектлауга якын килү» дип исемләнгән пленар фикер алышу узды. Оештыручы «Шәһәрне үстерү институты» учреждениесе, Казанның архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе оештырды. Утырыш эшендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Казан шәһәренең баш архитекторы Илсөяр Төхвәтуллина, Казан епархиясе музее директоры иеромонах Аркадий (Логинов), «Цимайло Ляшенко һәм Партнерлар» архитектура бюросына нигез салучы Николай Ляшенко һ.б. катнашты.

Камил хәзрәт Сәмигуллин әтрафлы белгеч буларак чыгыш ясады. Беренче чиратта ул Татарстан Республикасы Россиядәге иҗтимагый тотрыклылыкны тәэмин итүдә динара диалогны уңышлы тормышка ашыру үрнәге булып та тора, дип ассызыклады. «Милләтара һәм динара тынычлык һәм татулык – республиканың иң зур дәрәҗәсе һәм иң мөһим казанышы», – диде ул һәм Казанның Җәмигъ мәчете төзелеше темасына кагылды. Ул мәчет проектына карата үзенең тәкъдимнәрен җиткерде:

– Тәресез чиркәүләр була алмаган кебек, мәчет манарасы да ярымайсыз була алмый. Бу очракта бу бина (ТР Милли китапханәсе хакында) мәчеттән ни белән аерылып тора соң? Ул да кубка ошаган бит, ә бераз читтәрәк – манара тора.

Камил хәзрәт татар мәчете күренеше мәсьәләсен күтәрде һәм аның фикер алышу өчен ачык булып калуына игътибар итте, чөнки асыл татар мәчетләре чынлыкта икәү генә калган: Болгарда хан мәчете һәм Биләрдә тарихи мәчетнең нигезләре, ә XVIII-XIX йөзләрдә салынган мәчетләр мөселман булмаган архитекторлар тарафыннан төзелгән. Шул ук вакытта мөфти Җәмигъ мәчетен проектлаганда да татар мәдәнияте үзенчәлекләрен исәпкә алырга чакырды:

– Казанда иске мәчетләр шул вакыттагы мөселманнарның ихтыяҗларыннан һәм теләкләреннән, шулай ук безнең җирлекнең климат үзенчәлекләреннән чыгып салынган. Мәсәлән, аларда фарыз залы, сөннәт залы булган, бу ике зал берьюлы, экономия күзлегеннән чыгып, бары җомга көннәрендә генә җылытылган. Димәк, исәпкә алырга кирәк булган ихтыяҗлар бар һәм алар төрле вакытта үзгәрергә мөмкин. Бүген, әйтик, татар мәчете нинди булырга тиеш дигән сорау тора. Анда, һичшиксез, Казан кунакларына татар мәчетенең нинди булырга тиешлеген күрсәткән һәм аны башка беренинди бина – мәдәният үзәге, китапханә белән бутамаслык иткән милли орнаментлар һәм архитектура үзенчәлекләре урын алырга тиеш. Бу бина нәкъ менә дини корылма булып балкып торырга тиеш. Димәк, кунаклар нинди билгеләр буенча бинаның мәчет булуын танып алырга тиеш.

Камил хәзрәт манараның да үз максатлары барлыгын искә алды: «Беренче чиратта ул – маяк түгел, ә азан әйтү өчен. Ул, әлбәттә, башка функцияләрне дә үти ала, әмма беренче чиратта мәчет манарасы булып калырга тиеш».

– Әйе, манара һәм мәчет куб формасында да булырга мөмкиндер, – диде мөфти. – Ләкин бу очракта бинаны эксплуатацияләү үзенчәлекләрен дә исәпкә алырга кирәк. Мин, дин эшлеклесе буларак, мәчетнең матурлыгы һәм аның туристларны җәлеп итүчәнлеге мәчет өчен икенчел дип саныйм, ә төп өстенлек функциональлеккә, дин кардәшләргә гыйбадәтләрне үтәү (намаз уку, тәһарәт алу, машина кую, бинаны тоту) уңайлы булуга бирелергә тиеш. Моннан тыш, Җәмигъ мәчете янынннан су транспортында үткәндә яки самолетта очып барганда, кешеләр мәчетне танып алырга тиеш. Казан мәчетен!

> ***Казандагы татар мәчетендә милли орнаментлар һәм архитектура үзенчәлекләре урын алырга тиеш. Бу бина нәкъ менә дини корылма булып балкып торырга тиеш.***

Алга таба Камил хәзрәт катнашучыларны милли мәдәни үзенчәлекләрне глобализациядән сакларга чакырды: «Әгәр дә без бер-беребезгә охшаш булсак, бер-беребезгә кызык булмаячакбыз. Телләребез, мәдәният, кием, гореф-гадәтләребез төрле булганда, безгә илләр буйлап йөрү һәм өйрәнү кызыклы. Шуңа күрә Казанның Җәмигъ мәчете дә татар үзенчәлекләрен чагылдырырга тиеш».

«Әгәр Аллаһ теләсә, әлбәттә, бу Җәмигъ мәчете соңгысы булмас. Башка идеяләр дә тормышка ашырылыр.Тарихтан без Казанда беренче Җәмигъ мәчете – Мәрҗани мәчете икәнен беләбез. Ул тулгач, икенче Җәмигъ мәчете – Апанай мәчете салына. Аннары өченче Җәмигъ мәчет – Борнай мәчете барлыкка килә. Дүртенчесе – «Зәңгәр мәчет», бишенчесе – Галиев мәчете һ.б. Җәмигъ мәчете төзелүе киләчәктә тагын бер башка Җәмигъ мәчете барлыкка килмәячәк дигәнне аңлатмый бит», – диде ул.

– Кемдер: «Әйдәгез, киләчәккә карыйк», – ди. Кемдер аны тарихи яктан тормышка ашыруны тели. Төрле алымнар бар бит. Мәсәлән, «Кол Шәриф» мәчете безнең үткәнебезне гәүдәләндерә. Бу хакта озак бәхәсләшергә мөмкин. Ләкин иң мөһиме – мөселманнарның теләге. Ә бу исә: беренчесе – безгә уңайлы булсын, зур парковка, инфраструктура, функциональлек; икенчесе – татар үзенчәлегенең чагылышы! Без аны танып белергә, ул мәчет булырга һәм аны татар символлары бизәргә тиеш. Бу бик мөһим. Югыйсә бу объект башка биналардан аерылып тормаячак, – дип нәтиҗә ясады мөфти.

Фикер алышуның пленар өлешеннән соң Казанның Җәмигъ мәчете проекты презентациясе узды. Әмма аны үткәрү вакыты җомга намазы белән туры килү сәбәпле, дискуссиядә мөселманнар исеменнән Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов кына чыгыш ясады. Ул Мароккодагы Җәмигъ мәчетен мисал итеп китерде – ул да су өстендә төзелгән һәм үзенең архитектур матурлыгы белән сокландыра. Айрат хәзрәт шулай ук төзүчеләрне мөселманнарның фикерен исәпкә алырга һәм киләчәк буыннар өчен чын татар мәчете торгызырга чакырды.

# Бөек Болгар ядкәрләре

Ульяновск өлкәсенең И.А. Гончаров исемендәге төбәк тарихын өйрәнү музеенда Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында сакланган ядкәрләр күргәзмәсе ачылды.

Күргәзмәдә 550 дән артык археология ядкәре – X–XV гасырлардагы, ягъни Болгар каласы чәчәк аткан чордагы артефактлар урын алган. Әлеге экспонатлар Шәһри Болгарда һәм тирә-юнь территорияләрдә көн күргән халыкның төрле якларын – һөнәрчелек белән сәүдә эшләрен, көндәлек тормыш-көнкүрешен тасвирлый. Биредә керамикадан эшләнгән сууткәргеч торбалары, бронзадан ясалган көзгеләр, муенсалар, шахматлар һ.б. күрергә мөмкин.

Идел Болгарстаны дәүләте гасырлар буе халыкара әһәмияткә ия һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге булып исәпләнә. Күргәзмәгә җирле кәсепчеләр, кул осталары ясаган әйберләр белән беррәттән, иң ерак чит илләрдән кайтартылган ядкәрләрне дә куйганнар. XIII гасыр ахыры – XIV гасыр башында Кытайда фарфордан эшләнгән чынаяклар – әнә шундыйлардан.

И.Гончаров исемендәге төбәк тарихын өйрәнү музееның сектор мөдире Марат Гисматуллин фикеренчә, шундый зур масштаблы археологик күргәзмәләр – шәһәр өчен мөһим вакыйга, ә Болгарга багышланган коллекцияләр төбәк тарихын өйрәнү музеенда XX гасыр башында ук туплана башлый.

«Безнең музейханәгә нигез салучы танылган археолог В.Н. Поливанов XX гасыр башында археологик табылдыклар юнәтү максаты белән берничә тапкыр Казан губернасының Спас өязендәге Болгар авылына бара. Ул чакта Сембер губернасының гыйльми архив комиссиясе Тарих-археология музее дип исемләнгән музеебызда болгар чорына багышланган бүлек ачкан. XX гасыр башында безнең музейга кайтартылган экспонатлар бүгенге көнгә кадәр саклана. XX гасыр уртасында безнең шәһәр Болгар белән элемтәләрен яңартып җибәрә. Әлеге күргәзмәгә Д.И. Архангельскийның иҗат җимешләрен куйдык, анда Болгар авылы күренешләре һәм археологик казу эшләре сурәтләнгән, шулай ук әлеге казу эшләре нигезендә ясалган фәнни реконструкцияләү белән танышырга мөмкин. Танылган совет археологы А.П. Смирнов беренчеләрдән булып уникаль һәйкәлне – Болгар шәһәрлеген тикшереп өйрәнүгә керешә. Аның фәнни тикшеренү материаллары шулай ук безнең музейда саклана», – дип сөйләде М.Гисматуллин.

Күргәзмә 20 ноябрьгә кадәр эшләячәк.

**«Өмет» газетасы,**
**Ульяновск.**

## 2024 елга Ураза һәм Корбан гаете көннәре билгеле

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы Һиҗри буенча 1445-1446 елларга яки Миләди буенча 2024 елга мөселман бәйрәмнәре һәм истәлекле көннәр календарен раслады.

Һиҗри календарь 12 айдан тора һәм Мөхәррәм аеннан башлана. Мөселман календаре айларының башын һәм ахырын билгеләгәндә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы җирле географик үзенчәлекләргә һәм астрономик мәгълүматларга таяна.

2024 елда изге Рамазан ае 11 мартта башланачак. 2024 елның 10 апреле – Ураза бәйрәме. Тагын бер бөек мөселман бәйрәме булган Корбан гаете 16 июньдә билгеләп үтеләчәк.

Мөселман календаре буенча башка изге һәм истәлекле көннәр белән ТР мөселманнары Диния нәзарәте сайтында «Файдалы мәгълүмат» бүлегендә танышырга мөмкин.

## Милли мәдәниятләр фестивале

20–27 октябрдә Казанда икенче тапкыр «Казанда көнчыгыш базар» Халыкара милли мәдәниятләр фестивале узачак. Узган елдан аермалы буларак, фестивальнең географиясе һәм масштабы шактый киңәйде. Бер атна дәвам итәчәк быелгы фестивальдә төрки һәм көнчыгыш дөньясының 25 иленнән, Россиянең 15 төбәгеннән 40 милли мәдәният вәкиле катнашыр дип көтелә. Чараның төп оештыручысы – Р.Ваһапов исемендәге Татарстан Республикасы татар мәдәнияты иҗтимагый фонды.

Фестивальне ачу тантанасы республика җитәкчелеге, федераль һәм чит ил кунаклары катнашында 20 октябрдә Казан ратушасында узачак. Проект кысаларында Татарстан буенча «Ялла» төркеменең гастрольләре, «Евразиянең йөрәгеннән сәлам» программасы белән иң яхшы башкаручылар һәм коллективлар катнашында Башкортстан көне узачак. Фестивальнең йомгаклау концерты 27 октябрьдә якын һәм ерак чит ил кунаклары катнашында КРК «Пирамида» залында узачак.

«Казанда көнчыгыш базар» халыкара мәдәни хезмәттәшлекнең яңа юнәлеше. Бүген бөтен төрки һәм көнчыгыш дөньясы башкаручылары катнашында Россиядәге бердәнбер иң зуринтернациональ музыка фестивале, Россиянең Көнчыгыш һәм Азия илләре белән ныклы партнерлык элемтәләрен ныгыту дәлиле. Ул Татарстанда гына түгел, бөтен ил күләмендә елның төп халыкара мәдәни проектларының берсе булырга мөмкин.

## Мәскәү татарларының рухын сындырып булмый

110 еллык тарихы булган сәүдәгәр Әсәдуллаев йорты илнең төрле төбәкләреннән татарларны җәлеп итү үзәге булып кала. Аларның барысын да үзенчәлекле рух берләштерә, аны сындыру мөмкин түгел. Бу хакта Мәскәү татарлары автономиясе җитәкчесе Фәрит Фарисов башкаланың Татар мәдәни үзәгендә яңа иҗат сезоны ачылышында белдерде.

«Бездә Түбән Новгород, Казан, Әстерхан, Себер татарлары бар, әмма монда, Россия башкаласында, без барыбыз да Мәскәү татарлары булып саналабыз. Мәскәү татарларының үзенчәлекле рухы бар, аны сындыру мөмкин түгел», – дип аның сүзләрен китерә башкала автономиясенең матбугат хезмәте.

Фарисов искәрткәнчә, 2023 ел бу оешмада армия генералы Мәхмүт Гәрәевнең 100 еллыгы эгидасы астында уза. 2024 ел исә Татар мәдәни үзәгенең тагын бер күренекле активисты – Бөек Ватан сугышы ветераны, полковник Әнвәр Чанышев истәлегенә багышлана.

**tatar-inform.tatar.**

## Ата-аналардан – түләү

Казан Башкарма комитеты шәһәрнең мәктәпкәчә учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативын тәкъдим итте. Коррупциягә каршы экспертиза узган документның бер бүлеге 2024 елга ата-аналар өчен түләү булды.

Түләү бала шөгыльләнүче төркемгә, баланың яше һәм гаиләдәге балалар санына бәйле рәвештә төрлечә булачак. Икенче төркемдә бәяләр махсус дәвалау-сәламәтләндерү чараларына мохтаҗ балалар өчен, шул исәптән еш авыручылар өчен; үсешләрендә тайпылышлар булган балалар өчен; фонематик сөйләм бозылулары булган балалар өчен аерыла.

Иң арзан айлык түләү ике яшьтән өч яшькә кадәрге балалары булган ата-аналарга тәүлегенә өч сәгать эшләүче балалар бакчаларында, гомуми үсеш һәм катнаш юнәлештәге төркемнәрдә булачак: 468 сум, шул исәптән 289 сумы – азык-төлек бәясе.

**tatar-inform.tatar.**

## Ике депутат керемнәрен яшергән

Татарстанда ике депутатны керемнәр турында белешмәләрен яшергән өчен вакытыннан алда вәкаләтләреннән мәхрүм иттеләр. ТР Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы урынбасары Рөстәм Гаязов матбугат конференциясендә шулай дип белдерде.

Ул билгеләп үткәнчә, ел башыннан алып идарә тарафыннан керемнәр турында белешмәләргә тәгәллек кертү буенча 56 тикшерү үткәрелгән. Барлык материаллар да алга таба тикшерү һәм килеп туган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

«Безнең бүлекчә – коррупциягә каршы көрәшне кисәтү өчен җавап бирә торган махсус орган. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, депутатларны вәкаләтләреннән вакытыннан алда мәхрүм итү турында ике гариза җибәрелде. Депутатлар керемнәр турында белешмәләр тәкъдим итү кагыйдәләрен бозган өчен вазифаларыннан китте инде. Алар шактый зур күләмдәге сумманы яшергән һәм аны декларациядә күрсәтмәгән. Моны оялу яки башка сәбәпләр аркасында эшләмәгәннәрдер, мөгаен», – дип искәртте ул.

**tatar-inform.tatar.**

# Журналист читтән торып хөкем ителде

**Мәскәүнең Басман суды «Беренче канал»ның элеккеге мөхәррире Марина Овсянникованы 8 ел да 6 айга колониягә җибәрү турында хөкем карары чыгарды. Ул Россия Федерациясе Җинаять Кодексындагы 207.3нче маддәнең 2нче өлеше: кораллы көчләр турында дөрес булмаган мәгълүмат тарату эше буенча гаепләнде.**

Овсянниковага шулай ук 4 ел дәвамында сайтларда административ вазыйфаларда эшләргә ярамый, дип хәбәр итте башкала прокуратурасы.

Хөкем читтән торып – «заочно» чыгарыла, чөнки ул Россиядән киткән. Аңа карата җинаять эше 2022 елның июлендә Мәскәүдә София яр буенда уздырылган пикеты өчен ачылган, пикетның фотосын ул «Telegram»да урнаштырган. Плакатта Украина балаларының үтерелүе турында сүзләр булган. Прокуратура моның өчен аңа 9,5 ел төрмә сораган.

Марина Овсянникова 2022 елның мартында, «Беренче канал»да туры эфиры вакытында, хәрби бәрелешләргә каршы плакат белән чыккач танылды. Август аенда суд аңа,



Россия армиясе турында фейк таратуга бәйле рәвештә (РФ ҖК 207.3нче маддәсенең 2нче өлеше), өй аресты билгеләде. «Коммерсант» язуынча, журналист үзен гаепсез дип белдереп, сак чарасын үтәүдән баш тартты. Октябрьдә ул өй арестыннан Франциягә качты.

**1 нче биттә** – Муса Җәлил кызы Люция ханым Мостафа авылында, әтисенең бюсты янында. В.Имамов фотосы.

# Ялчыгол дәвамчылары

Туганлык җепләрен өзми саклаган нәселләр булу куандыра. Кардәш-туганлык хисен тою, туганнар бөтенлеге – зур көч ул. Язучы, дин галиме Таҗетдин Ялчыгол дәвамчылары – туганлык кыйммәтләрен саклаучы шундый нәселләрдән.

Җиһанда кызгылт-сары төс иңгән алтын көз... Ялчыгол дәвамчылары, традицион укулар кысасында, Зәй районының Иманлебаш һәм Куш-Елга авылындагы зиратта ерак бабалары рухына дога кылды, узган ел төзекләндерелгән Хәзрәт чишмәсе суын татыды. Югары Мәлем авылындагы очрашуда сигез һәм тугызынчы дистәне ваклаучы апа-агайлар, урта һәм яшь буын вәкилләре җыелды. Шәҗәрә бәйрәме аралашып, фикерләшү, нәсел дәвамчыларын барлау, киләчәк буынга дөнья бәһасенә торырдай киңәшләр бирүдән гыйбарәт булды. Мондый очрашу ике дистә ел элек Мәлемдә Ялчыгол оныгы Сөнгатулла нигезендә оештырылган иде.

Разилә апа Җиһаншина ерак бабасы Таҗетдин Ялчыголны ак чалмалы, яшькелт күлмәк кигән ир итеп күз алдына китерә, хәтта, төшләренә дә шулай керә икән.

– Дөньяга игътибар итмә син, без дә бар әле, – дип эндәшкән Ялчыгол ага, бер төшендә. Югыйсә, Рәзилә апа – Таҗетдиннең бишенче буындагы оныгы, әлбәттә, ул бабасын күрә дә алмаган. Ә менә Ялчыгол нәселе дәвамчыларының Мәлемдә үткәрелгән чираттагы очрашуына сөенеп бетә алмый.

– Җиде буын бабасын белгәннәр бәхетле, без – шул бәхетле нәселләрнең берсе, – ди Разилә апа.

...Ил буенча йөреп, дини һәм дөньяви белем туплаган, халыкка аң-белем тараткан Ялчыгол гомеренең соңгы елларын Югары Мәлемдә яши. Биредә ул һәм кызлар үстереп, төп нигез һәм зур нәсел калдырган. Дин әһеленең биек таулар кочып алган, итәгендә чәчәкле, җиләкле, мәтрүшкәле болыннар җәйрәп яткан матур табигатьле Мәлемгә төпләнүе очраклы түгел. Аксакаллары әйтүенчә, Т.Ялчыгол Мәлем тауларына менеп көч алган, алар итәгендә үскән шифалы үләннәр белән кешеләрне сихәтләндергән, гипнозчы буларак та авыруларга булышкан. Мәдрәсәдә шәкертләргә дини белем биргән, халыкка Аллаһ сүзләрен ирештереп, дин-исламга хезмәт иткән, һәфтияк шәриф калдырган. Ә Мәлем халкы шифа өстәүче, шәфкатьле дин әһелен яраткан, үз иткән. Моны тойган хәзрәт аларга рәхмәт йөзеннән шигырь юллары тудырган.

*Мин фәкыйрне олылыйлар,*
*Шифа сүзем –*
*бөтем малым.*
*Бу карьяның мәшһүр аты*
*Ил башында булгай Мәлем.*

Иң мөһиме, Ялчыголның тәрбия-белем орлыгы шифалы, бәрәкәтле җиргә төшеп, матур шытымнар биргән. Үзе дә иманлы, укымышлы нәсел калдырган. Мәлемдә – улы Җәләлетдин, Күперледә икенче улы Баһаветдин имамлык иткән. Соңрак Мәлемдә Җәләлетдиннең эшен уллары һәм оныклары дәвам кылган.

Зыялы Ялчыгол дәвамчылары Россиядә генә түгел чит илләрдә дә хезмәт куя. Язучы Диләрә Зөбәерова, Татарстанның элекке юстиция министры Әнәс Таҗетдинов, Татарстан Рәисенең Аппарат җитәкчесе Әсгать Сәфәров – әлеге нәселдән. Башка дәвамчылары арасында атказанган белгечләр, табиблар һәм укытучылар да шактый. Дәвамчыларда ерак бабаларының күркәм сыйфатлары, кылган изге гамәлләрендә тәрбиялелек, зыялылык сизелеп тора.

– Нәселебез турында быел «Тамырлар» китабы нәшер ителде, басманы «Туганнар очрашуында» тәкъдир итү бик урынлы булды, – ди Алсу ханым Талипова.

Бүген әлеге нәселдә 300 гә якын дәвамчы исәпләнә, быел гына да бу нәселдән берничә сабый өстәлде. Буыннар чылбыры өзелми.

Мәлемдә Сөнгатулла нигезе гомер-гомергә туганнарны бергә җыеп торган. Мәдәният йортында оештырылган быелгы очрашу да буыннарның аралашуы, әби-бабаларының хатирәләрен барлау рәвешендә барды. 90 яшен тутырган Разин абый Таҗетдинов, 80 яше белән баручы Мингасыйл абый Талипов, Казан кунагы Илсөяр ханым бәрхет тавышлары белән җырлап, күпләрне яшь чакларына кайтарды. Мәлем укучылары чыгышында Ялчыголның мәдрәсәдә дин сабагы биргән мизгелләре яңартылды. Шул рәвешле кунаклар ихластан чыгыш ясап, мондый очрашуның дәвамлы булуын теләде.

**Рәзимә КАШАПОВА.**

# «Ока»лы премьера һәм Төркия

Минзәлә театры үзенең 88 нче иҗади сезонына шактый билгеле әсәрнең премьерасын гадәти булмаган форматта әзерләде. Туфан Миңнуллинның беренче тапкыр 2003 елда Камал театры сәхнәсендә куелган, алга таба Татарстан, Башкортстан театрлары репертуарында урын алган «Шулай булды шул» мелодрамасында чын... «Ока» машинасы сәхнәгә чыкты!

– Ни өчен чын «Ока»? – дигән сорау белән режиссер Илсур Казакбаевка мөрәҗәгать иттек.

– Гадәттә, беренче сорау «Ни өчен бу әсәргә алындыгыз?» – дан башлана иде, ди И.Казакбаев. – «Ока» – чөнки пьесада сүз «Ока» турында бара да инде. 90 нчы еллар, әсәр күпләргә таныш, шактый театрларда куелды. Башкаларның мөмкинлеге (бәлки, теләге) булмагандыр, ә менә Минзәлә театрының мөмкинлеге табылды – сәхнәгә чын «Ока» чыга! Туфан аганың материаллары, гомумән алганда, халыкчан, аларда чын тормыштан алынган вакыйгаларга зирәк акыл белән бәя бирелгән җитлеккән җаваплар ятә. «Шулай булды шул»да вакыйгалар Алмаз атлы егет исеменнән сөйләнә, беренче карашка әсәр Алмаз турында бара. Ә минем исә, куючы режиссер буларак, алданудан бәгыре каткан, хәзер беркемгә дә ышанмаган Гөлшат исемле кызның, әкияттәге Кар кызы кебек, чын мәхәббәттән йөрәге эрүе турында сөйлисем килде. Кызның йөрәгендә боз, сәхнәдә – кыш вакыты. Егет белән кызның танышуы гайре табигый вакыйгадан башланып китә, икесе ягыннан да конфликт, аңлашылмаучылык, ашыгыч ясалган ялган туй, алга таба – хатлар язышу һәм тора-бара чын хисләр яралу. Гадәти булмаган вакыйганы сурәтләп, автор безгә зур каршылыклар аша узып бәхетле булган Алмаз белән Гөлшат турында сөйли, ә тел төбендә без уйлап эш итәргә кирәклеген, кешеләрне аера белергә өйрәнергә кирәклеген ата-ана нәсихәтен тыңларга кебек кабул итәбез. Т.Миңнуллинның әсәрләренең кыйммәте дистә еллар үткән саен да үзгәрми, киресенчә, арта гына бара, чөнки кеше мөнәсәбәтләре еллар гына түгел, гасырлар дәвамында да шулай кала...

88 нче иҗади сезон бүләкләрсез генә башланмады: Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә «Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исем Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры артисты Руслан Илгиз улы Әхмәтҗанова бирелде. Россия Мәдәният министрлыгының «Бөек рус язучысы Ф.М.Достоевский» истәлекле медале белән Достоевский әсәре буенча куелган «Җинаять һәм җәза» спектаклендә Ата, Супермен, Мармеладов рольләрен уңышлы башкарган өчен артист Ринат Бәдретдинов бүләкләнде. Театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен Татарстан Мәдәният министрлыгының Мактау Грамотасы артист Илдар Халиковка һәм реквизит цехы мөдире Анна Шәймәрдәновага тапшырылды.

Ә тагын да сөенечлесе – Минзәлә татар дәүләт драма театры XV «Этос» Анкара Халыкара театр фестивале кысаларында 14 октябрьдә Ф.Бүләковның «Сөясеңме, сөймисеңме» трагикомедиясе белән Анкара шәһәренә китте. Фестивальнең баш темасы «Үткәннән – киләчәккә» дип билгеләнгән. Ул Анкара һәм Чанкайя муниципалитетлары, төрле иҗтимагый берләшмәләр ярдәме белән оештырылган. Фестивальдә Төркиянең Истанбул, Анкара, Искешәһәр, Чанаккале шәһәрләреннән, Ираннан, Гыйрактан, Әзербайҗаннан театр коллективлары катнаша.

16 октябрьдә театр коллективы Истанбул шәһәрендә төрки халыкларның музей комплексындагы «Топкапы» мәдәни паркында концерт программасы белән чыгыш ясады.

**Нурсибә АДИЕВА,**
театрның әдәби бүлеге мөдире.

# Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияләр тапшырылды

**19 октябрь көнне Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреатларын һәм стипендиатларын бүләкләү тантанасы узды. Татарстан Язучылар берлеге әлеге нәзматлар исемлеген ачыклады.**

**Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреатлары: Алия Кәримова** «Птица сердца» (татар теленнән тәрҗемәләр), «Вересковая пустошь» шигырьләр җыентыгы өчен; **Йолдыз Шәрәпова** «Сәяхәтче чемодан», «Китаплы кич» шигырьләр җыентыгы өчен; **Миңзифа Әхмәтшина** «Иңнәремдә ак җилкән» шигырьләр җыентыгы өчен.

**Кызыксындыру премиясе лауреатлары: Гөлнур Айзат** «Баллы кирпеч» повестьлар һәм тарихи хикәяләр җыентыгы өчен; **Ольга Овчинникова** «Зеленый ёж» балалар өчен әкиятләр һәм шигырьләр җыентыгы өчен; **Илдус Диндаров** «Торна күзе» повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы өчен.

**Әдәби стипендиягә лаек булган студентлар:** Мәскәүнең Горький исемендәге Әдәбият институты студентлары **Илмир Газизов, Руфия Мортазина,** КФУ студентлары **Ландыш Гобәйдуллина, Алинә Закирова,** Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты студенты **Полина Яковлева.**

- Казанда сентябрьдә 9,7 миллиард сумлык фатир сатылган – бу өч елда иң зур күрсәткеч. Базарга РФ Үзәк банкының катгый акча-кредит сәясәте зур йогынты ясый: башта кредит ставкасы 12%ка, ә 18 сентябрьдән 13%ка кадәр күтәрелде. Валюталар курсындагы тотрыксызлык һәм ипотека программаларында беренчел кертемнең 15%тан 20%ка кадәр артуы да күчемсез милек базарына йогынты ясамый калмый. Казанда торакның 1 квадрат метры бәясе инде икенче ай буе 186 мең сум тәшкил итә.
- «Яңалыклар» РМАның Россия шәһәрләрендәге эш хакы күләме буенча рейтингында Казан 22 нче урынга куелган, башкалабызда ул уртача 63 мең сумга тәңгәл, дип исәпләп чыгарганнар. Беренче өчлеккә исә Яңа Уренгой (уртача айлык хезмәт хакы 143 мең сум), Мәскәү (138 мең сум) һәм Салехард (127 мең сум) кертелгән.

# Төбәк тарихчылары җыены

*Сентябрь ахырында Әгерҗе районының Шаршады авылында төбәк тарихчыларының зур җыены үтте. Әгерҗе районында татар краеведларының болай күпләп җыелганы юк иде. Шаршады авылы, дигәндә, моның сәбәбе дә бар – чөнки ул тарихка үзенең данлыклы Тәфкилевләр утары, шунда кунак булган Гаяз Исхакые, утар хуҗасы, армия генералы, кумык милләтеннән булган Шәех-Алилары, аның улы, татарга гарәп хәрефле язу машинкалары ясап биргән Әскәр Шәех-Алилары белән кереп калган!*

Шуңа күрә җыенда Шәех-Алиның Дагыстаннан килгән якташы – Абдрахман Хаҗи улы Мөхәммәтнең катнашуы да гаҗәп түгел, чөнки Шәех-Али – Дагыстанда милли каһарман. Ә Абдрахман Хаҗи улы Мөхәммәт исә Дагыстанның Удмуртиядәге вәкиле икән. Шаршады халкы кадерле кунакларны бәлешләр пешереп каршы алды, ә табынны Дагыстаннан килгән җиләк-җимешләр бизәде. Бу җыенда Мәскәүдән якташлары, татарлар һәм төрки халыклар милли конгрессы рәисе Рөстәм Ямалиев та катнашты.

Төбәк тарихчыларының очрашуы авыл музееннан башланып китте, анда мәктәп балалары кунакларны шигырьләр сөйләп каршы алды. Аннары төбәкчеләр эшләрен мәдәният йортында дәвам итте, ул «Түгәрәк өстәл» форматында узды. Түбән Кама шәһәреннән мөселман яшьләре үзәге җитәкчесе, шулай ук Кама аръягында татарлар һәм төрки халыклар милли конгрессы рәисе Даут Хәбибуллин Коръән укыды, Әгерҗе районы имам-мөхтәсибе Габделкәрим хәзрәт Гыйззәтуллин дога кылды. Кичкетаң авылы имам-хатибы, элеккеге мөхтәсиб Азат хәзрәт Гатин Шаршады авылы мәчетенең тарихын сөйләде, бу тарихи бинаны саклап кала алмауларына борчылу белдерде. 1891 елда Сәетгәрәй Тәфкилев кызы Өммегөлсем Шәех-Али акчасына салынган бу гаҗәеп матур мәчет бинасы совет чорында мәктәп тә, китапханә дә, кибет тә була, 2009 елда ул янып юкка чыга, аның урынына фельдшер-акушерлык пункты салып куялар.

Шаршады тарихчысы, туган авылы турында китап язып тәмамлаган Зөлфия Нәфыйкова «Бер тарихта мең тарих» дип аталган бу очрашуны презентация рәвешендә алып барды, без экраннарда Тәфкилевләр утарындагы Ак сарайны да, Гаяз Исхакый тезләнеп намаз укыган Ак мәчетне дә, Шаршадының тарихи үткәнен, бүгенгесен дә күрдек. Авыл бүген дә нык, аның башлангыч мәктәбе, яңа мәчете, мәдәният йорты, бай китапханәсе, музее бар. Табигате матур, тарихы бай. Инде Зөлфия ханымның Шаршады турында китабы да басылып чыкса, бу тарихны татар халкы да беләчәк. Элемтәләр эзләп, Зөлфия Дагыстанда, Шәех-Алиның туган авылы Эндирейдә дә булып кайтты, бу затлы нәселгә караган башка кешеләр белән дә элемтәдә тора. Тарих менә шулай языла.

Балачагы һәм яшьлеге Шаршадыда үткән талантлы уйлап табучы, Казанда «Пишмаш» заводы нигез салучы һәм аның директоры, репрессия корбаны Әскәр Шәех-Али улы турында да китап язылган булып чыкты. Ул 2019 елда Казанда басылып чыккан, рус телендә, «Эхо веков. Судьба изобретателя», дип атала, аның авторы – Маргарита Шәмсетдин кызы Бәдретдинова. Билгеле булганча, Әскәрнең хатыны – Суфия Шаһбазгәрәй кызы, данлыклы Әхмәровлар нәселеннән, Заһидә Тинчуриның бертуган апасы. Гаяз Исхакый да Шаршадыга шушы яшь гаилә янына кайтып йөри, алар Петербургтан дуслар була, болар хакында Рабит Батулла язмаларыннан да укып белергә мөмкин.

Соңгы бер елда татар конгрессының Әгерҗе бүлеге гомерен яшь буынга татар телен һәм әдәбиятын укытуга багышлаган Вәсилә ханым Хәкимова җитәкли. Ул төп игътибарны татар авылларына, аларның тарихын һәм бүгенге тормышын өйрәнүгә юнәлтте. Без аның белән шушы вакыт эчендә унбишләп авылда булдык, проблемаларны өйрәндек, аларны В.Хәкимова район җитәкчеләре алдында күтәрде. Шаршадыдагы төбәк тарихчылары җыенын да өч кеше – Әгерҗедән Вәсилә Хәкимова, Шаршадыдан Зөлфия Нәфыйкова һәм Кичкетаңнан эшмәкәр, Әгерҗе районы төбәк тарихчылары оешмасының җитәкчесе Рамил Маннапов үз өстенә алды. Кызганычка, Казаннан, Бөтендөнья татар конгрессыннан килүчеләр булмады. Рамил әфәнде җыенда Әгерҗе төбәгенең мең еллык бөек тарихы, ул тарихта күрше удмурт, мари, чуаш халыкларының да зур өлеше барлыгын сөйләде. Үзе дә Әгерҗе районының мәчетләре һәм чишмәләре турында китап язган.

Җыенга районның Әгерҗе, Кичкетаң, Иж-Бубый, Биектау-Мордыбый, Уразай, Кодаш, Тәберле, Салагыш, Тирсә, Кырынды, Исәнбай, Иске Эсләк, Нарат, Шаршады авылларыннан төбәк тарихчылары, музей хезмәткәрләре, китапханәчеләр килгән иде. Моннан тыш, «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы, Удмуртиянең "Яңарыш" газетасы редакциясеннән дә вәкилләр килгән. Әгерҗе районы татар авыллары турында инде 15 китап язылган. Эльза Сибгатова – «Бөек Себер юлында Биектау», Тәнзилә Ибраһимова – «Чал тарихлы Уразаем», Гөлфидә Мәрданова – «Иске Эсләгем – гомер бишегем» китапларының язылу тарихын сөйләде, Раиф Гәрәев һәм Алсу Хисмәтуллина Иж-Бубый тарихын, Шаршадыдан Раушания Баһаветдинова Шәех-Али турында, Әгерҗе үзәк китапханәсеннән Миләүшә Шәйхетдинова фаҗигале язмышлы татар шагыйре Даут Гобәйди хакында, Даут Хәбибуллин туган авылы турында чыгыш ясады. Мәскәү кунагы Рөстәм Ямалиев исә әнисенең туган авылы Салагыш, әтисенең туган җире Уразай турында кызыклы мәгълүматлар бирде. Ул шулай ук Әгерҗе төбәгендә туып-үскән танылган шәхесләр турында документаль фильм төшерергә җыенуларын хәбәр итте, алар турында төгәл мәгълүмат сорады. Рөстәм әфәнде үзе белән «Үз җиремдә – үз телем» дип аталган китапларын да алып килгән иде.

Мин дә Әгерҗе районында төбәк тарихын өйрәнүнең торышы һәм Биектау авылында туып-үскән күренекле тел белгече, күп дәреслекләр авторы, педагог-профессор Мөхетдин Корбангалиев һәм аның нәсел дәвамчылары турында сөйләдем. М.Корбангалиевнең тууына быел 150 ел тула, әмма аны Казанда зурлап билгеләп үтәргә җыенмыйлар. Аны Әгерҗедә яки туган авылында булса да билгеләп үтү турында сүз булды. Мөхетдин Корбангалиевнең репрессия корбаны булган кызы Мөкәррәмәнең фаҗигале язмышы да күпләр өчен яңалык булды.

Әйе, татар җәмгыятендә төбәк тарихын өйрәнүчеләр бик аз санлы, әмма затлы катлам. Бу эшкә теләсә кем тотына да, башкарып чыга да алмый. Авыл җирендә яшәп, тарих язу бик авыр, чөнки бөтен архивлар, зур китапханәләр, кирәкле оешмалар барысы да шәһәрләрдә. Интернетта да бөтен нәрсә юк, барыбер кирәкле материалны күп очракта аягың белән йөреп табарга туры килә. Инде язып бетергәч, китап итеп чыгарырга акчасы кирәк, авыл халкында андый акча юк, ә хакимият ярдәм итәргә атлыгып тормый. Ярый да авылдан берәр бае булып, ул ярдәм итсә, әмма ул очракта китапның күп өлеше аның турында булырга мөмкин. Менә шундый зур каршылыкларны уза-уза гына дөньяга килә ул төбәк тарихы турында китаплар! Ә аларның авторларын күп очракта Казан белми дә, презентацияләр турында сүз дә була алмый. Югыйсә, вакытларын, гомерләрен туган авыллары турында китап язуга багышлаган бу фидакарь затлар рәхмәтнең иң олысына, кадер-хөрмәтнең иң зурысына лаек бит!..

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА.**

# Рухи мирасны халыкка кайтаручы

## *(Вәлиулла хәзрәт Якуповның тууына 60 ел)*

*Вәлиулла хәзрәт Якупов – XX гасыр ахырында совет уку йортларында тәрбия алып, яшьлек елларында ук Ислам юлын сайлаган, алга таба күренекле дин әһеленә әверелгән шәхес.*

В.Якупов Башкортстанның Уфа районы Дмитриевка авылында 1963 елның сентябрендә Мәхмүт белән Бибиәсма гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килә. Гаилә этисенең эше белән бәйле Бирск шәһәренә күченгәч, шундагы 4 нче мәктәпне 1981 елда тәмамлый. Шул ук елда С.Киров исемендәге Казан химия-технология институтына укырга керә. Монда җәмәгать эшләрендә катнаша, институтның комсомол оешмасы секретаре булып сайлана. Укыган вакытта ук үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештыра. Аның «Умырзая» ансамбле чыгышларында татар халкының милли үзенчәлекләре чагылыш таба. В.Якупов үзлегеннән татар телен һәм татар грамматикасын үзләштерә, китаплар язу дәрәҗәсенә җитә.

Вәлиулла хәзрәт милләтнең диннән башка тулы мәгънәдә үсә алмаганын яшьләрнең милли хәрәкәтендә катнашкан вакытта ук аңлый. Ул исламны тирәнтен өйрәнә башлый. Бәхеткә, бу чорда Казанда исламны аңлата алырлык, борынгы мәдрәсәләрдә гыйлем эстәгән кешеләр булган әле. В.Якупов XX гасырның 80 нче еллар ахырында Казанның төрле мәдәни-мәгърифәт үзәкләрендә ачылган гарәп теле курсларының берсенә языла. Институтны ул 1987 елда «Электрохимик җитештерү технологиясе» белгечлеге буенча инженер химик-технолог квалификациясе белән тәмамлый. Соңыннан институтта эшли, аспирантурада укый, Казан дәүләт университетының тарих факультетына читтән торып уку бүлегенә керә. Тарих фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклый. Ул Ислам кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсен дә тәмамлый.

1990 еллар үрендә халыкның үзаңы күтәрелде, иҗтимагый-милли оешмалар барлыкка килде. Ә иҗтимагый-дини оешмалар һаман юк, Казанда бер – Мәрҗани мәчете генә эшли иде. Партия рөхсәтеннән башка хаҗга бару да катгый контрольдә тотылды һәм аңа лимит буенча СССРда елына 25 кешегә генә рөхсәт алу мөмкин иде.

1990 елның ноябрь аенда Казанда «Иман» дип исемләнгән ислам мәдәнияте үзәге ачыла. Ул җөмһүриятебездәге иң беренче дини оешма санала, һәм аның максаты мөселман яшьләрен берләштерү, шулай ук дин белгечләренә дә, гади мөселманнарга да гыйлем-мәгърифәт, дини мәгълүмат эзләү юлында ярдәм итү була. Оешманың җитәкчесе итеп Вәлиулла хәзрәт Якупов сайлана. Ул мөселманнарның дини китапларга ихтыяҗын канәгатьләндерүне үзмаксат итеп куя. «Иман» нәшрияты оештырыла. Дини эчтәлектәге беренче китаплар илаһи ядкәрләр кебек кабул ителә.

Ул вакытта системалы рәвештә чыга торган дини матбугатка да ихтыяҗ барлыгы беленә. «Өебезгә даими килеп торачак дини газета кирәк», дигән үтенечләр килә. Шуны исәпкә алып, Вәлиулла хәзрәт дуслары белән «Иман» газетасын нәшер итә башлый. Мөселманнар, динне өйрәнергә теләүчеләр аны зур кызыксыну белән каршы ала. Беренче елларда газетаның тиражы 4-5 мең булса, соңрак 20 меңгә кадәр җитә. «Иман»ны Татарстанда гына түгел, Россия өлкәләрендә яшәүче мөселманнар да яратып укый.

«Иман» мәркәзенең программасында Казанның мәшһүр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен торгызу иң мөһим мәсьәләләрнең берсе итеп куела. Бу эш тә В.Якупов җилкәсенә ята. Вәлиулла хәзрәт Казанның халыкка 1995 елда кайтарылган Апанай мәчете имам-хатыйбы һәм «Мөхәммәдия» Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры булып та хезмәт куя. Күп каршылыкларны җиңеп чыгып, 1993 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, 50 кеше кабул итеп, яңадан эшли башлый. «Иман»да басылган китаплар ярдәмендә уку-укыту эше алып барырга мөмкинлек ачыла. Беренче уку елларында аның үз бинасы да булмый әле. Укулар Ленин исемендәге мәдәният сараенда арендага алынган бүлмәләрдә башлана. Алга таба «Мөхәммәдия»нең төп бинасын кайтару өчен өч елдан артыкка сузылган көрәш башлана. Озак судлардан соң, бина мәдрәсәгә кайтарыла. Аны уку йортына яраклаштыру өчен зур ремонт эшләрен оештырырга туры килә. 1996 елдан мәдрәсә үзенең төп йортында эшли башлый. Менә 30 ел мәдрәсә республикабыз яшьләре арасында гына түгел, ә бөтен Россия һәм БДБ гражданнары арасында да укыту һәм тәрбия алып бара.

Апанай мәчетен мөселманнарга кире кайтару өчен көрәш, Вәлиулла хәзрәтнең йөз суын түгә-түгә Мәскәүгә йөрүләре –үзе бер аянычлы тарих. Андагы ремонт эшләре 2011 елга хәтле сузыла. Мәчет 1930 елны тартып алынгач, михраб, манара сүтеп ташлана, ике катлыдан өч катлы ителеп, балалар бакчасына әйләндерелә. Борынгы проектларны табып, бүгенге хәленә китерү өчен бинниһая хезмәт салына. Бу титаник эшләрнең башында Вәлиулла хәзрәт Якуповка торырга туры килә.

«Мөселман календарьлары» исә 1996 елдан бирле нәшер ителеп килә. Анда илнең төрле төбәкләре өчен намаз вакытлары, догалар, Коръән сүрәләре, вәгазьләр, хәдисләр, мөселман укучысына файдалы һәм кызыклы мәкаләләр урын ала. Вәлиулла хәзрәт нәшриятта татар халкының тарихына, мәдәниятенә, есемнәре халык хәтереннән җуелырга мәҗбүр ителгән атаклы дин галимнәре шәхесләренә караган бик күп китаплар да бастырып чыгара. Әйтик, укучыларга зур галим Риза Фәхреддиннең «Җәвамигуль кәлим-шәрхе» китабы белән «Иман» нәшрияты аша 1995 елда танышу насыйп булды.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә нигез салучы Галимҗан Барудиның җәдит мәктәпләре өчен күпсанлы дәреслекләре, ислам дине тәгълиматын заманга яраклаштыру кирәклеген аңлаткан һәм шуңа ирешү юлларын күрсәткән дини-фәлсәфи хезмәтләре дөнья күрде. Татар мәдрәсәләре, шәкертләр тормышын чагылдырган татар язучылары китапларын да, басарга әзерләп, кереш сүз язып В. Якупов нәшер итә.

Репрессия корбаны булган татар дин әһелләренең хезмәтләрен бастырып чыгару да – «Иман» нәшриятының мөселман мәгърифәтчелегенә керткән өлеше. Мәсәлән, танылган дин галиме, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе, репрессия корбаны Мөхәммәдсадыйк Иманколый 1910 елда «Тәсһилел бәян фи тәфсирел Коръән» исеме белән 744 битле зур китап бастырып чыгара. 1996 елда «Иман» нәшриятында бу китапның икенче басмасы да дөнья күрде.

Татар дөньясында киң билгеле Ногмани тәфсире 1911 елда Казанда дөнья күрә. Тел үзенчәлекләре буенча бу тәфсир гавам халкына бик якын, ягъни гамәлдә булган татар әдәби теленә хас була. «Тәфсир Ногмани»ны иҗат итүче мулла Ногман кем була соң? «Бу шәхес Стәрлетамак төбәгендәге Сәмән исемле авылдан Әмир бин Госман исемле кешенең улы. (Сәмән хәзер Авыргазы районына керә). Казан төбәгенең Курса авылында мәшһүр галим Әбүннасыйр Габденнасыйр бин Ибраһимнан зур тырышлык белән сабак укыган, үзенең үткенлеге, зиһенлеге аркасында зур уңышларга ирешкән. Әбүннасыйр хәзрәтләреннән күп файда, белем эстәгән. Коръән-Кәримдәге бәгъзе нечкә мәсьәләләрне тирәнтен аңлый белергә өйрәнгән», – дип язган Җәгъфәр хәзрәт Мөбәрәк үзенең «Габделхәбир хәзрәт Ярулин турында хатирәләрем» дигән китабында (Казан: «Иман», 2016). Сәмән авылында туган Ногман мулланың язмышы турында болай диелгән: «Остазының ир туганы Әшшәйх Габделхалик хәзрәтләренә кияү булган. Остазы хаж сәфәренә киткәч, аның урынына мөгаллим булып шәкертләргә дәрес биргән. Остазының кайбер әсәрләренә мөхәррирлек иткән һәм аның «Һәфтияк» тәфсирен тәмамлау максаты белән Коръән-Кәримгә тәфсир яза башлап, «Кәһф» сүрәсенә җиткергән. Остазыннан соң бераз Курсада мөгаллимлек иткәннән соң, Дагыстан тарафына киткән һәм анда вафат булган». Шулай итеп, Вәлиулла хәзрәт үзе туып-үскән Башкортстан җирлегендә дөньяга килгән мәшһүр дин галимнәренең хезмәтләрен дә халыкка җиткерүгә күп көч салган, аларны «Иман» нәшриятында бастырып чыгаруга ирешкән.

Иманколый хәзрәтнең «Мөнәҗәтләр» китабы да 2000 елда «Иман» нәшриятында дөнья күрде. Мәдрәсәләр эшли башлагач, дәреслекләргә кытлыкны да «Иман» нәшрияты ярдәмендә хәл итәләр. Күренекле дин галиме, гарәп теленнән күп дәреслекләр авторы, Башкортстанның Авыргазы районы Балыклыкүл авылында туган Сөнгатулла Бикбулатның (1886-1954) китаплары да нәшриятта басылып чыкты һәм бу хезмәтләр бүген дә мәдрәсә шәкертләренең «өстәл китабы» булып тора.

В.Якупов Россиядә беренче Ислам әдәбияты нәшриятына нигез салучы, күпсанлы дини һәм тарихи хезмәтләр авторы, актив публицист буларак та билгеле. «Иман» нәшриятында 33 ел эчендә 1150 исемдәге хезмәт басылган. 1990-1995 елларда гына да татар телендә дөнья күргән китапларның гомуми тиражы 432 600 данә була. Бу – белгечләр кытлыгы, типография, кәгазь табу авыр булган заманда. «Иман» нәшриятында дөнья күргән татарча китапларның исемлеге 500дән артып китә. Моңа әле газета-журналларны, календарьларны өстәргә мөмкин.

Исән булса, Вәлиулла хәзрәткә быел 4 нче сентябрьдә 60 яшь тулыр иде. Ул 2012 елның 19 июлендә ясалган һөҗүм нәтиҗәсендә фаҗигале төстә һәлак булды.

В.Якупов халыкка кайтарган «Мөхәммәдия» мөселман белем учагы бүген яңартылган биналарда яшь буынга дини гыйлем бирү юлында үзенең эшчәнлеген дәвам итә, Апанай мәчете – имам-хатыйб Нияз хәзрәт Сабиров, Апанай мәдрәсәсе директоры Әхмәт хәзрәт Сабиров җитәкчелегендә Вәлиулла хәзрәт салып өлгергән традицияләргә тугры рәвештә эшли.

**Рәмзия ИСЛАМГАЛИ.**
Казан шәһәре.

Равил РАХМАНИ

# Исемнән җисемгә җиткәнче Мең тапкыр адаша бу йөрәк...

## ШӘМАИЛЛӘР – ӨНСЕЗ ДОГАМ

Ай нурыннан үргән яшәү анты –
Язма-чатыр балачактан якын;
Каурый каләм жыр күк борма-борма
Очкынлана... җанда каба ялкын!

Өзек-өзек гасыр калкынуы,
Бабайларның җиткән серле хаты;
Чәбәләнгән урау язмышлары
Юл сабадыр җиргә кире кайтып.

Бу дөньядук сират күпрен үтеп
Тормыш кичкән кара шомлы илдә
Гаҗәпмени, горур милләт рухы
Яшәү тапса шушы шәмаилдә?!

Кыйбласына туры нур-тәрәзә –
Кайта-кайта үзен яклау өчен;
Вөҗданының тере таныклыгы –
Миссиясен җирдә саклау өчен!

Ни күргәнен әйтми үтә серле...
«Террор!» диеп кыза вәсвәсәче;
Бу төртенгән канлы-яшьле җирдә
Җиңлеп җиңдең, яшәү фәлсәфәсе!

Баш имәдең сурәт-табынуга,
Ымсынмадың шәрә курчакларга;
Буйсынмадың мәкер-тозакларга,
Тышкы шаукым, эчке кысаларга!

Йолып калдың үчлек вакльгыннан,
Дәва булдың милләт ярасына;
Күңелләргә өмет-күпер суздың
Фани–бакый дөнья арасында.

Сабыйлыктан сеңгән аһәң – канда:
«Шөкер, яши, сау!» – дип сөенәмен;
Уентыклы сабыр урман-күлләр,
Дугайланган иркен тау-елгалар,
Кысылса тын... сезгә килеп сыенам мин!

Табигатьтәй даһи рәссам,
хикмәт иясе бу...
Идел-йортны – Илен тапкан
Әхлак үзе:
Чәбәләнеп төшә олы бәхет булып
Мәңгелекнең тере суы – Ходай сүзе!

Күзләремнән сарка өнсез догам:
Үткәннәр дә шыксыз,
кырыс күрәчәк тә...
Киң җиһанда мең-мең кырлы алмаз –
Иман яра Хак юл
туры киләчәккә!

## СИНЕҢ ИСЕМ

Җиһанда һәрнәрсә исемле,
Исемсез туса җан – югала.
Сиңа да, зурлап, ат куштылар:
Гомерле булсын, дип, бу бала!

Әтиең-әниең дога күк
Телеңнән төшерми исемең;
Тик шушы баш сүздә ачыла
Сөйдергеч әфсене кешенең!

Кабатлый урамнар, җил, яңгыр...
Теркәлдең җирләргә, күктә син;
Китерер исемең һәр таңда
Бәхетеңнең өр-яңа нөсхәсен!

Үз күреп яд итәр тиңнәрең,
Күпсенеп – ят итәр кемнәрдер...
Зур сөю кабызган ярыңа
Бу исем дөньяда – бердәнбер!

Халкыңның ул –
Өмет-Вөжданы...
Ул – житмеш буыннан Әманәт;
Исемеңә аркадаш булалсаң,
Кералмас арага яманат!

Яңарыш – үстерү тапканны!
Теләктән максатка – юл ерак...
Исемнән җисемгә җиткәнче
Мең тапкыр адаша бу йөрәк:

Калырсың язларда – түгелеп,
Җәйләрдә – кибегеп,
көзләрдә – күмелеп...
Ачылсын асылың –
зәмһәрир суыкта
Калкырсың җаннарда гөл кебек.

Чутлама яшьлегең көннәрен
Ел белән – яшимгә саналып...
Кушылма заманга,
торткындай –
Кушамат, тагылган сан алып.

Әврелмә күмәклек исемгә –
Туган тел түзмәс бу җәбергә!
Булма буш кушымта паспортта –
Ил белән туганнар кабрендә...

Артмасын җиһанга затсыз ат:
Мәгънәсе юк – хәреф тезмәсе;
Игелекле, рәхмәтле исемеңне
Милләтең догадан өзмәсен.

Булсын ул каһарман – илеңдә,
Бер гөле – үз туган җиреңдә;
Шәүлә күк йөрмәсен буталып
Ят кавем капкасы төбендә.

Йөзе ак киләчәк каршында,
Күңле киң
хөр Идел-йортының!
Дога күк иштелә телләрдә
Иманлы исеме токымның.

Кумый ул сабыйны бишектән
Кемнедер һичшиксез ууларга;
Изгелек – Ходасы каршында –
Олы Хак кодрәте аңарда!

Таш түгел, тәкъдиргә
җөй сыман
Уелган мөһерле тамгасы;
Дәүләтле-шәүкәтле – җисемле исемең
Бер Хакка дан булып яңрасын!

## ШӘҖӘРӘ

Сабый көннән газиз күргән әби-бабам:
«Балам!» диеп аваз салды җан-тәрәзгә...
Хәтер терелеп, өч-дүрт буын
кан-кардәшем
Тирәк булып үсеп чыкты ак кәгазьдә:

Күккә ашкан ябалдашлар – сокландыра,
Яши нәсел – күз алдында... яфрак яра.
Бу кодрәтле чал тирәкнең
тамырлары кайда?!
Юк күренми... җир астында алар бар да.

Дәшми тора мин белмәгән әби-баба...
Белмәгәнгә бүген язмышларны кара?
Җан иңдергән, үстергәннәр...
ишле иткәннәр –
Шыбырдаша күпме яфрак,
әнә, кара!

Аңлыйлармы туфрак аша тамыр телен? –
Җан сизгечең белән сүлне барлау кыен;
Ник көз кергәч... үкенечле – сары дөнья,
Октябрьдә* ... ник түгә күк зарлы көен?!

Куяр иде сафта иңне-иңгә терәп,
Бердәм типсә җирдә бүген
милли йөрәк;
Сабантуйга кайтып төшкән
кардәшләр күк
Җир шаулатып гөрләр иде
миллион тирәк!

Һәр заманның җанда үз ялкыны –
Яшәү утын өсти торган, ала торган;
Нинди кодрәт иңдерә алсын шәхесләргә
Посадкалы вак куаклык катнаш урман?

Түгелсә дә күпме кардәш каны җиргә...
Сугаралмый нәсел тамрын җир астында;
Дәүләт исән карурманлы чакта –
Лаек яшәп ай һәм кояш яктысында!

Янган меңнәр
яшьлек ялкынында,
Мең тармаклы сөю-нәфрәт,
холык булып...
Шәҗәрәңдә – синең җиңү,
коллык…
хурлык –
Җитди бәя... җир өстендә халык зурлык!

Юк, шауламый-үсми –
үчә милли урман,
Гәрчә... саны арта бара куакларның;
Кай катламда бабайларның,
хәят нуры чәчеп,
Үчлек уты урган ялгыз учаклары?!.

* Татар милләтенең фаҗигале Хәтер көне, Хәтер ае (автор искәрмәсе).

## ХӘТЕР

I

Яр буйлары куак кына –
Оя-оя чатыр...
Дала иңләп илгә кайта
Шәҗәрәле Хәтер.

Сары-кызгылт яфраклары –
Безгә дигән хаттыр;
Һәрберсе – йөрәк... җөйләрен
Ятлап укыр чактыр.

Тиздән барсы, сибелешеп,
Җиргә төшеп ятыр...
Җыерчыклы тарих сере –
Җәрәхәтле Хәтер.

Өсләренә яңгыр явар,
Кырау, чык чылатыр;
Фани дөнья гамьсезлеге
Сагыш-моң кузгатыр.

Тынып калыр аннан җиһан,
Кабат ак кар балкыр...
Язылмаган ап-ак кәгазь
Кемгә нәрсә әйтер?!

...Сулар акмый тормас җирдә,
Кайтыр язлар, кайтыр;
Бозны тишеп чыгар сабак,
Тамырларда – Хәтер!

II

Кардәш булып килеп таптың эзләп,
Йөрәгемә утлар аттың төзәп:
– Биш гасырга авыш кыйблаң төзәт!..
Бу кадәр дә ник син үҗәт, Хәтер?

Нәслең-тамрың, кыйлган эшең саный,
Күрше карттай кырыс, – таяк яный;
Алга чыга йөгреп, арттан калмый,–
Ун мең яшең... холкың – сабый, Хәтер!

Өзеп бәгърең, сызлап тора эчтә,
Телә җанны иртәсен дә, кич тә...
Юк, калдырмый урын башка хискә –
Уйдан үткен, моңнан нечкә Хәтер!

Эзәрлекләп күпме куып барыр...
Ничәвебез туктап уйга калыр...
Уй төбендә, белмим, нәрсә табыр?..
Үз-үзеңнән ник син авыр, Хәтер?!

Кабынырга җитә сыңар чаткы –
Балачактан картлыгыңа чаклы
Чолгый тәнне уты катлы-катлы...
Газабың да – татлы ялкын, Хәтер!

III

Югалтудан вакыт, диләр, дәва –
Фаҗигадән ерагая ара...
Буын арты буын ятып кала,
Хәтер үлми – Хәтер алдан чаба!

Карында ук сине килеп таба:
Нәсел өне күчә жаннан җанга...
Дәһшәт эзе төшә каннан-канга...
Юк, төзәлми... тирәнәя яра.

Барган саен, алда еллар кара,
Асыл затлар поскан кайсы кая...
Йорт-Ватансыз үткән гомер зая –
Җәрәхәттән, сыкрап, Өмет тама.

# «Татар газеталары да

*«Татар журналистлары» сәхифәсендә тарихта үз эзен калдырган каләм ияләре белән таныштыруны дәвам итәбез. Чираттагы кунак – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Мәдәни җомга» газетасында хезмәт куйган журналист Сөембикә КАШАПОВА.*

***– Сөембикә апа, Сез кайсы яклардан буласыз, иҗатка мәхәббәт ничек уянды, кемнән күчте икән?***

– Саба районы Керәнле авылында туып үстем. Безнең авыл бик матур, Кече Мишә елгасы ярында урнашкан. Балачагыбыз туган як болыннарында күбәләкләр белән ярышып, чәчәкләренә сокланып, тауларында җиләкләр җыеп, елгасында коенып үтте. Әти-әниләр көннәр буе эштә иде, без – балалар өйдәге эшләрне карап, печән җыеп, утын ярып, эшләп үстек.

Гаиләбез ишле иде, 6 бала. Хәтерлим: әтием Кыяметдин, мин үскәндә, шигырьләр, мәкаләләр язу белән мавыкты. Алар районыбызның «Җиңү байрагы» дигән газетада басылды. 1960 елларда «Җиңү байрагы»ның юбилее уңаеннан Сабага Казаннан язучылар кайтты. Бәйрәм кичәсенә әтине дә чакырдылар. Шушы бәйрәмнең истәлеге булып әтинең Хәсән Туфан, Сибгать Хәким, Нәби Дәүли белән бергә төшкән фотосы, редакциянең әтигә бүләк иткән «Татар халык мәкальләре»нең калын томлыгы саклана.

Тормышыбыз җиңел бармады. Күмәк хуҗалыкта эшләгәнгә «таяк куеп» түли торган еллар. Әти авыру иде, шуңа күрә дә ул ихатада барлык эшләрне башкара алмады. Бик күп хезмәт әни җилкәсенә кала иде. Өйгә көндәлек матбугатны күп алдыра, «Социалистик Татарстан, «Яшь ленинчы» газеталарын, «Ялкын», «Казан утлары» журналларын беренче битеннән соңгы битенә кадәр укып бара идек.

Минем китап яратканымны күреп, әти сөенеп йөрде. Бервакыт әти Казанга барып кайтты. Сумкасы бик авыр. Әни: «Әтиегез бик күп күчтәнәч алып кайткан, ахры», – ди. Ә ул шул елларда нәшер ителгән «Татар поэзиясе антологиясе» дигән саллы китап булып чыкты. «Антология»не ачып-ачып укый торган идем. Моннан тыш И.Гази, Н.Дәүли, Г.Әпсәләмов, Ә.Еники һ.б. әдипләрнең әсәрләрен бик яратып укыганым истә.

Арча районының Яңа Кенәр урта мәктәбен тәмамлагач, укуымны бик тә дәвам итәсем килде. Әмма мөмкинлегем булмавын аңладым. «Колхоз рәисе, укытучы балалары гына югары уку йортларында белем ала, минем кебекләр берсе дә университетка укырга керми. Аларның өс-башлары яхшы, алар янында бу киемнәр белән ничек йөрермен?» – дип уйладым да җитен комбинатына эшкә кердем, җеп эрләүче булып 5 ел эшләдем. Алай да, журналист булу теләге сүрелмәде. Редакцияләргә кыска хәбәрләр язып җибәрә идем, алар «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре»ндә чыкты.

Шулай итеп, үзем Казанда җеп эрләүче булып эшлим, ә күңелем һаман белемгә омтыла. Конструктор, аннары секретарь-машинистка булырга курсларда укып карадым, берсе дә күңелгә ятмады. Шуннан соң, рабфак студенты булдым. Әлбәттә, әтиәнием укырга кергәнемне белгәч шатланды.

Казан университетының журналистика факультетында Васил Гарифуллин, Миңназыйм Сәфәров белән бергә укыдык. Төркемебез бик дус иде, барыбыз бер гаилә кебек булдык. Хәтерлим: «Тозелешта» күп тиражлы газетасына практика үтәргә җибәрделәр. Төзүчеләр турында материаллар яздым. Төркемдәшем Илдус Сафин язмамны укып чыкты да: «Син болай яза белгәч, нәрсәгә укырга кердең соң?» – дип аптырады. Төркемдәшләрем ихластан сөенә, мактый иде.

Укыганда бервакытта да әтиәнидән акча сорамадым. Эшлиэшли укыдым. Лекцияләр тәмамлангач, икенче сменага Мех берләшмәсенең чимал эшкәртә торган цехына эшкә бара идем. Аллаһыга шөкер, гомерем буена беркайчан да акчага интекмәдем. Кызлар хәзер: «Иң яхшы киенүче син идең», – диләр. Бераз эшләп акча туплагач, Мәскәүгә барып, киенеп кайта идем.

***– Кайсы редакцияләрдә эшләдегез?***

– Университетны тәмамлаганнан соң кая барырга? Татарстанда 2 төп татар газетасы бар: «Социалистик Татарстан» һәм «Татарстан яшьләре». Житәкче урыннарда таныш-белешләрем юк, республика газеталарында штатлар тулы. Мине Мамадыш районы газетасы редакциясенә эшкә җибәрделәр. Һәр район халкының үз холкы бар. Әйтик, Сабада – гадирәк, җылырак халык. Турысын бәреп сөйләшәләр. Ә менә мамадышлыларның дипломатлыгын, салкынрак халык булуын күрдем.

«Коммунистик хезмәт өчен» газетасы редакциясе – бик көчле коллектив, Зәки Хәнәфиев – баш мөхәррир иде. Әлеге коллективта Чәчкә Хөснетдинованың язмаларын бик яратып укыдым. Шигырьләр дә яза иде ул. Әмма республика дәрәҗәсендә үсеп җитә алмады. Зиннур Хәсәнов атлы журналистның тиз, эшлекле язуына соклана идем.

Мин үземне бервакытта да яхшы яза торган журналист дип исәпләмәдем, иҗатымнан беркайчан да канәгать булмадым. Әмма күңелне сөендерә торган вакыйгалар булгалады. Бервакыт Татарстан өлкә комитетының матбугат секторы вәкиле редакциябезнең эшчәнлеген тикшерергә килде. Кичен редактор бүлмәсендә партия җыелышы башланды. Чәчкә белән мин партиядә түгел, безне кертмиләр. Ишеккә колакны куеп тыңлыйбыз. Обком кешесе минем материалны мактарга тотынды! Мораль темасына язылган мәкаләмне сүтеп җыйды. Бик ошаткан иде.

Редакциядә эшләгәндә мин язмаган тема калмагандыр: терлекчеләр, кырда эшләүчеләр, гади эшчеләр... Берсендә «Спартак» колхозының алдынгы сыер савучысы Роза ханым Гарипова турында «Еллар китергән бәхет» дигән язма бастырдым. Беркөнне героемнан редакциягә хат килеп төште. «Мәкаләне семьябыз белән укып шатландык, чөнки С.Кашапова аны күңелгә якын итеп язган», – диелгән иде. Алдынгы сыер савучы турында миңа кадәр дә шактый гына журналистлар язган булган, әмма иң ошатканы – минем материал булып чыкты.

Мине хатлар бүлеге мөдире итеп билгеләделәр. Ай саен редакциягә килгән хатларга (ул елларда газетага хат-хәбәрләр күп агылып торды) күзәтү ясый идем. Шулай ук, шикаять хатлары буенча материаллар әзерләдем. Гомумән, Мамадыш редакциясе бик әйбәт мәктәп булды. «Комсомол прожекторы», автоинспекторлар, милиция хезмәткәрләре белән төрле мәсьәләләрне тикшерергә рейдларга да чыга идек. Күз ачып йомганчы дигәндәй, 3 ел үтеп китте. Әмма... Мамадышта каласым килмәде. Казанга кайтырга – зуррак дөньяга чыгарга омтылдым.

***– Ә Казан ничек каршылады?***

– «Мехчы» газетасына корреспондент кирәк булуы ачыкланды. Күп тиражлы газетада булса да эшләрмен, барыбер Казанга кайтам, дидем. «Мехчы»ның баш редакторы Венера ханым Кәлимуллина белән килешеп эшләдек. Цехларга чыгып, эшчеләр белән аралаштым, төрле тантаналар, бәйрәм кичәләре турында яздым. Мех берләшмәсендә эшләүнең тагын бер уңай ягы булды – туристик юлламаларны бик арзанга алып, ел саен кая да булса сәяхәт итеп, ял итеп кайта идем. Балтыйк буе илләре, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Кавказ яклары... Йөрмәгән җир калмады бугай. Берсендә Адыгея башкаласы Майкопта 5 көн тордык та, аркага рюкзак асып, Кавказ тавы аркылы Сочига җәяү чыктык. Украинага барып, кырларында помидор җыеп, Одесса урамна-

● «Коммунистик хезмәт өчен» редакциясе хезмәткәрләре.

# гайбәт оясына әйләнә»

● Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән.

рын иңләп тә йөрдек. Яңа җирләрне күрергә, белем тупларга омтылып гомер иттем.

СССР таркалгач, гөрләп эшләгән предприятиеләр дә екренләп кысыла башлады, «Мехчы» газетасында да кыскарту булды. Татарстан Дәүләт Советы карамагында оештырылган «Татарстан хәбәрләре» газетасы редакциясенә эшкә керергә булдым. Редакция Бауман урамындагы Матбугат йортында урнашкан. Бу вакытта улым Рәшит туган иде. Ирем белән бергә озак яшәмәдек. Тулай торакта уңайлы булса да, анда яшисем килмәде, коммуналь фатир сорап йөри башладым. Ышандыралар, әмма һаман бирәселәре килми. Баш редакторыбыз Ренат Харис бер генә шалтыратты, шундук «коммуналка» бирделәр, Аллаһыга шөкер.

Эшкә урнашкач, Белем көненә багышланган материал язарга туры килде. Редакциядә эшләүче Мәгъсүм Гәрәев язманы «теле бик матур» дип мактарга тотынды. Коллектив та әйбәт, зур форматлы газета булгач, кеше дә күп эшли иде: Рәсимә Сибгатуллина, Салисә Гәрәева, Флера Тарханова, Касыйм Тәхау, Мәгъсүм Гәрәев, Нияз Акмал, Сәрмәдия Сөләйман һ.б. белән бергә хезмәт куйдык. Баш редакторыбыз Ренат Харис редакциябезне уңайлы җиһаз, кирәк-яраклар, журналистларны диктофоннар белән тәэмин итте. Бик сөенеп, рәхмәтле булып эшләдем.

Бер елдан артык «Татарстан хәбәрләре»ндә каләм тибрәткәннән соң, газетаны яптылар. Аның базасында «Мәдәни җомга» атналык газетасы оешты. Анда Зиннур Мансуров редактор булып килде, урынбасарыбыз Газинур Морат булды. Яңа кешеләрне дә чакырдылар, мәсәлән, Саимә Ибраһимованы һ.б. Көндезге ашлар, чәй эчеп алулар бик күңелле үтә иде.

Әмма алга таба матбугат өлкәсендә хәлләр уңай якка китмәде. Әйтик, элек Татарстанның Матбугат министрлыгы бар иде, анда күп дигәндә 17 кеше хезмәт куйган. Аннан соң «Татмедиа» оешты. Анда хәзер йөзләрчә кеше эшли. Безнең редакциядә элек 40лап кеше исәпләнә иде, кыскарта торгач, штатта бармак белән санарлык хезмәткәр калды. Ни кызганыч, хезмәт хакларыбыз да артмады...

***– Без, журналистлар, бер-беребезне кимсетмәсәк тә, безне кимсетүчеләр бихисап...***

– Мине кимсетәләр икән, шундук җавап бирә алмыйм. Уйлап йөрим-йөрим дә барыбер әйтәм. Аңа карап, журналистикадан беркайчан да китәсем килмәде, эшемне гомер буе бик яратып башкардым. Йөрергә яраттым. Төрле чараларга барам, конференцияләргә йөрим. Үземә нинди дер белемнәр эстәп кайтам. Шуңа сөенәм!

Татар журналистлары көчле язмый, дигән сүзләрне дә күп ишеткәнем булды. Бу фикер белән беркайчан да килешмәдем, хәтта шаккатып утырган чакларым бар. Әйтик, Вахит Имамов шикелле тирән итеп, матур тел белән, тиз һәм әйбәт итеп яза белгән бер генә рус публицистын, журналистын да белмим. Чөнки рус журналистлары без язган бик күп темаларны яктыртмый. Без телебез, гореф-гадәтләребез, йолаларыбызны саклау өчен көрәшәбез. Рус журналистлары бу теманы бөтенләй белми, чөнки аларга ул куркыныч янамый. Аннары Зиннур Мансуров кебек һәр җөмләсен, һәр сүзен уйлап, тирән итеп яза торган журналистлар да сирәк. Аның мәкаләләренең өтерен дә төзәтеп булмый.

Соңгы елларда рус журналистларының күбесе мәгълүмати материаллар язу белән мавыга башлады. Үзем язган темаларны рус журналистлары ничек язды, тәкъдим итте икән дип, кызыксынып карыйм. Әмма мин аларны «ah» итәрлек көчле журналистлар» дип әйтә алмыйм.

Без тирәнрәк материаллар язарга, халкыбызны күтәрергә, килеп туган мәсьәләләрне күрсәтергә, аны хәл итү юлларын табарга тырышабыз. Рус журналистлары матбугат, фәнни-гамәли конференцияләр булганда да, мәгълүматны, артык тирәнгә кереп тормый гына, кыска итеп яза. Ә без конференция материалында да төп мәсьәләне күрсәтергә омтылабыз.

Тагын күңелне борчыган мәсьәлә бар. Соңгы вакытта татар газеталары да гайбәт газетасына әйләнеп бара сыман. Аларда җиңелчә темалар күренә башлады! Бу артист бала тапкан, яңа күлмәк алган, пластик операция ясаткан, бер кыз белән егет ташлашкан, аннары кавышканнар, балалары туган һ.б. шуның кебек темалар. Бу – кешенең шәхси эшләре, мондый язмалардан милләтебезне үстерү өчен бернинди файда юк. Дәүләт газеталарының шундый язмалар белән тулуы өчен борчылам.

– Татар журналистларына игътибар турында сөйләшәсе килә, – дип дәвам итте Сөембикә апа. – Җитәкчеләр тарафыннан татар журналистларына игътибар бик аз. Бер мисал китерәм. Яңа ел вакытында, 8 нче Март бәйрәмендә журналистларны Республика Рәисе хозурына җыялар. Әмма анда татар журналистлары бик аз – бармак белән генә санарлык була. «Мәдәни җомга»дан үз гомеремдә бер генә журналистның да шунда булганын хәтерләмим. Бу хакта Рәиснең матбугат сәркатибенә дә әйтеп караганым булды. Андый чарада катнашкан журналистларның күбесе Россия мәгълүмат агентлыкларында, федераль каналларда эшли. Татарстанда сенсацион вакыйга була икән, алар шундук хәбәр җибәрә. Алар нигездә мәгълүмати язма була. Ә безнең тирән итеп язган материалларга игътибар күрмим.

Мәсәлән, 2020 елда «Мәдәни җомга»ның беренче саны дөнья күрүгә 25 ел булды. Бу турыда мин массакүләм мәгълүмат чараларында бер материал да күрмәдем, котлау сүзе ишетмәдем. Шушы хәлгә шаккаттым.

Журналистлар арасында бик күп бәйгеләр уздырыла, мин дә катнаштым, 40лап дипломым бар. Шул исәптән, «Бәллүр каләм»дә дә җиңгән идем. Конкурсларда жюрида күбесенчә төрле газеталарның баш мөхәррирләре утыра. Алар үзләренең хезмәткәрләренә урын бирә, ә башка газеталарның журналистлары читтә кала. Мин хәзер конкурсларда катнашмыйм. Дөрес, беркайчан да шикаять белән йөрмәдем. Һәрвакыт кешенең үзенә турыдан бәреп әйтәм, эчемдә тотмыйм.

***– Сезне Россия төбәгендә яшәүче татарлар да, республикадагы җирле татарлар да белә. Сез бик актив язасыз, командировкаларга йөрисез.***

– Әйткәнемчә, йөреп тору, кешеләр белән аралашу, яңа белемнәр эстәү, дөнья күрү – үзе энергия бирә. Минем фикерләрем туа, кайткач, шуларны кәгазьгә теркәп куям. Узган ел көзен төбәкне өйрәнүчеләр белән бергә Урал тавы якларына бардык, кайткач, 7 күләмле материал яздым. Чөнки алар күңелемә төйнәп кайткан фикерләрем иде. Әйтик, Уралда йөргәндә Чиләбе өлкәсе Мөслим авылында булдык. Бу авыл радиациягә эләккән булган. Башка авылларны күчереп бетерсәләр дә, Мөслим халкы радиация вакытында да шунда яшәп калган. Шушы авыл турында да бик борчылып яздым. Хәзер Мөслим авылын башка урынга күчергәннәр. Ә мәчетне сүтәргә берсенең дә кулы бармаган, мәчет утырып калган. Ә язманы болай башладым: «Автобусыбыз белән кыр уртасындагы юлдан узып барабыз. Кинәт ялан җирдә ялгыз торган мәчет сискәндерде. Манарасы да, ае да бар...» Күчерелгән Мөслимдә әле һаман да авыру кешеләр яши.

Шулай тетрәндергеч тарихны күңелемә төйнәп куям. Аннан соң, язмасам, кәефем дә булмый. Чарага барасың, язасың, һәм ул газетада басылып чыга. Журналистның чын бәйрәме инде бу.

***– Сезне татар дөньясы, мәдәният темаларына гына язасыз дип белә идем.***

– Бик күп темаларга яздым. Заманында ЮХИДИ, пенсия, социаль темаларга язып, шул өлкәләрдәге белгечкә әйләнеп беткән идем инде. Сорау белән мөрәҗәгать итсәләр, аңлатып, җавап бирә ала идем. Хәзер телебез, гореф-гадәтләребез темасы якын. Ә инде мине иң нык борчыган мәсьәлә – телебезнең бетүе. Телне саклау, тел проблемаларын яктырту буенча үземнән кечкенә генә булса да өлеш кертәм дип уйлыйм. Еш кына татар теле миңа кирәкми, дигән сүзләр ишетәм. Үз телеңне «кирәк» дип өйрәтмиләр.

Транспортта барганда әби кешенең оныгы белән русча сөйләшүе шундук кәефне кыра. Бу кешенең милли үзаңы үсмәгәнлеген, аң-белеме тирән булмаганлыгын күрсәтә. Аллаһыга шөкер, улым Рәшитне татарча белә торган итеп үстердем. Без өйдә татарча гына сөйләшәбез. Улым – физика-математика фәннәре кандидаты.

***– Сезнең белән бергә кичә-бәйрәмнәргә туры килгәнем булды. Анда кайчак татар галимнәре, язучыларның балалары русча сөйләшә башлый, әйтмичә калмыйсыз, йөрәкне тырнап торадыр ул...***

– Әйтеп үткәнемчә, җаным авырта. Әйе, русча сөйләшү ул бик уңайлы, ләкин бала үз телен белергә, аны онытмаска тиеш. Әдәби конкурсларның да күбесе дә рус журналистларын, рус язучыларын үстерүгә юнәлдерелгән. Яшь татар каләм ияләрен үстерү буенча бәйгеләр бик аз. Болай барса, тора-бара, татарлар арасында язучылар да бетүгә йөз тотачак.

Балалары белән туган телебездә шулкадәр матур итеп сөйләшкән ата-аналарны күргәнем булды. Мин аларга рәхмәт әйтеп китәм.

***– Хәзерге яшьләрнең, хезмәттәшләрегезнең язмаларын күзәтәсездер...***

– Бер чарада берничә журналист белән эшләргә туры килде. Коллегамның исемен әйтмим, әмма аның материалы тирәнтен өйрәнелмичә, тикшерелмичә, өстән-өстән генә язылган иде. Тәнкыйтьләп язган инде үзенчә. Ә теманың асылын аңласаң, мәгънәсенә төшенсәң, тәнкыйтьләр урын да юк иде... Шушы күренешкә шаккаттым. Тышкы билгеләргә карап кына нәтиҗә чыгармыйлар. Бу хәлдән соң ул журналист белән сөйләшә алмыйча да йөрдем.

***– Кыю фикерле журналистлар бармы?***

– Кыю фикерле дип Вахит Имамовны әйтә алам, ул әйтәсе сүзен барыбер белдерә. «Мәдәни җомга»да булмаса, башка газетага язып булса да әйтә. «Татар-информ» журналисты Рузилә Мөхәммәтованың да материаллары кыю. Соңгы елларда үткен каләмле журналистларны рус газеталарында күргәнем юк.

***– Татар журналистикасының киләчәге бармы?***

– Татар журналистикасының киләчәге борчуга сала. Казан федераль университетында бакалавриатның көндезге бүлегенә татар журналистларына бюджет урыннары да бетерелде. Татар матбугатында эшләүчеләрнең хезмәт хаклары аз. Бу инде «татар матбугаты бетсен» дигән максат куела торгандыр, дигән уйлар тудыра.

***– Яшьләр колагына нәрсә әйтер идегез?***

– Бер урында гына эшләп утырып журналист булып булмый. Ул очракта күңел мүкләнә, фикер тарая башлый. Журналист һаман йөреп торырга, дөнья күрергә, чараларда катнашырга, аң-белемен күтәреп торырга тиеш, шул рәвешле, фикер дәрәҗәсе үсә. Каядыр барып, яңа әйберләр күргән журналистның гына чагыштырулары барлыкка килә, фикере тирәнәя. Яшь журналистларга күбрәк йөрергә, матур әдәбият һәм журналистик, публицистик материаллар укырга киңәш итәр идем. Җитәкчеләребез тарафыннан да журналистларга күбрәк башка төбәк журналистлары белән аралашу, яңа җирләр күрү мөмкинлеге тудырылсын иде.

**Зилә МӨБӘРӘКШИНА.**

intertat.tatar.

# ДӨЯ КҮЗЕ

Чыңгыз АЙТМАТОВ

**(Дәвамы. Башы 35, 36, 37, 38, 39, 40 нчы саннарда).**

– Юк, үкенәчәкмен. Беләм, гомер буе үкенеп яшәячәкмен. Шулай да синең белән кайтып китәм. Ялгызым калырга теләмим...

– Әкренрәк сөйләш! Якынрак кил. Ну, күптән шулай кирәк иде юкса... Бөтен мендәрне юешләп бетергәнсең.

Мин одеялымны башымнан ук бөркәнеп яттым. Кәефемне җибәргән әлеге сүзләрнең дәвамын ишетмәс өчен, тизрәк йоклап китәсе иде.

5

Кояш көннән-көн катырак кыздыра бара. Сорокин да безнең янга ешрак килә башлады. Вакыт аз калып бара, җир кибә – ашыгырга кирәк иде. Безнең тагын биш көнлек сөрәсе җир бар, чәчүчеләрнең дә эше шул чама иде.

Сорокин әйтә, көзгә туңга сөрәчәкбез, ә киләсе елда бирегә бик күп тракторлар китереп, РТС оештырачаклар, ди.

Сорокинның барысы да исәпләнгән. Ул бертуктаусыз далада, аның тугайларында, чокыр-чакырларында, үзәннәрендә йөри. Ул даланы белә дию генә аз, ул бөтен даланы күңеленә сеңдергән, аның соңгы ком бөртегенә хәтле тикшергән-өйрәнгән.

Авыр кышларны еш кына Анархайга машина һәм самолётлар белән терлек азыгы ташыйлар иде. Хәзер инде мондый эшне туктатырга вакыт. Сорокин моңа ничек ирешергә кирәклеген дә белә.

Без Әбәкер белән кара төн җиткәнче җир сөрәбез. Шунда кырда гына кунып калабыз да таң ату белән яңадан тотынабыз. Эш шулхәтле авыр – Әбәкер мине бөтенләй борчымас булды. Ул миңа бөтенләй игътибар итми, бар дип тә белми кебек. Шулай да эчендә яшертен бер дошманлык асраганы караңгы чыраеннан сизелеп тора. Ләкин миңа аннан бернинди дә зарар юк. Мин үз эшемне эшлим, үз хыялларым белән яши бирәм! Мин чабаннар янына, калкулык артындагы тугайга барып, маңгаенда чәч чугы йөрткән теге кызны эзләп табасы көнемне көтәм.

Бу көннәрдә без зур яңа бер кишәрлек сөрә башладык. Үзең яраткан, җанга канәгатьлек бирә торган эш белән шөгыльләнгәндә, яңага керешү һәрвакыт күңелле бит ул. Мин әле мәктәптә укыган чагымда ук, өр-яңа дәфтәрнең чиста битенә яңа юлдан язып китәргә ярата торган идем. Иртән беркем аяк басмаган яңа кар өстенә эз төшереп йөгереп йөрергә, яз көне тау итәкләренә барып, әле беркем күреп өлгермәгән беренче лаләләрне җыярга ярата идем. Беренче булуның яңалыгы, сафлыгы белән күңелне кызыктыра, дәртләндерә торган үзенә бертөрле хикмәте бар. Биредә, Анархайда, кеше кулы тимәгән кырдагы беренче буразна минем өчен кәгазь битендәге беренче юл, кеше аяк басмаган яңа кар һәм кеше күреп өлгермәгән лалә чәчкәсе сыман иде.

Мин менә сабан өстендә үземнән астагы төрәннәрнең беренче буразнаны ничек ярганын карап барам. Күзне чагылдырырлык булып шомарган, ялтырап торган төрәннәр җирне кисеп кереп, туфрак катламнарын җиңел генә, йомшак кына итеп кайтарып салып баралар.

Кырый төрән астында кинәт, дулкын өстендә балык атылган кебек, нәрсәдер ялтырап китте, төрән көзгесендә ут шикелле чагылып алды да шундук буразна эченә кереп югалды. Мин сабан өстеннән ялт кына сикереп төштем дә шул турыга йөгереп барып, җир астыннан авыр, озынча металл кисәге тартып чыгардым. Бик матур, соклангыч бернәрсә иде бу, мин шатлыгымнан кулларымны өскә күтәрдем дә:

– Алтын! – дип кычкырып җибәрдем.

Әбәкер минем тавышка борылып карады, аннары тракторны туктатты да җиргә сикереп төште.

– Нәрсә таптың?

– Алтын таптым! Менә, Әбәкер, алтын бу!

Әбәкер миңа таба атлады. Әкрен генә килә башлаган иде, ашыга-ашыга атларга кереште. Мин әлеге алтын – сары матур әйберне, учыма салып, аңа суздым.

– Яле! – дип, Әбәкер шикләнгән бер төс белән табышны кулына алды да җиңенә ышкыштыргалап карарга кереште. – Каян килсен монда алтын? – дип сөйләнеп куйды буылган бер тавыш белән, үзенең, кинәт куркып калган кешенеке шикелле, йөзе агарынып китте. – Булмас, – дип көчәнеп кенә елмайгандай итте, тырнагы белән

ярыклардагы балчыкны кыргалап карады һәм шуннан соң, минем күзгә карамаска тырышып, сизелеп торган ризасыз бер төс белән металл кисәген миңа кире кайтарды.

– Ә нигә булмасын! – дип каршы төштем мин, кайнарланып. – Менә кара, нинди авыр, сигез йөз грамм чамасы бардыр. Уникенче гасырда монда монголлар яшәгән, ә бирегә килгәнче, алар Кытайны басып алганнар, аннан бик күп алтын алып киткәннәр. Әнә шулай моның бирегә эләгүе бик ихтимал! – Мин табышымның алтын булуын бик теләгәнгә күрә шулай дип сөйләндем. Шул теләк белән мавыгып китеп, үз хыялымнан өстәп сөйләргә керештем, сүземнең хаклыгына үз-үземне дә, шаккатып калган Әбәкерне дә ышандырасым килде. – Беләсеңме, җир астында ничә гасыр буе яткан ул? Башка металл булса, ул әллә кайчан күгәреп-череп беткән булыр иде инде, ә моңа берни булмаган, чөнки саф алтын ул. Монда, Анархайда, элекке заманнарда күчмә кабиләләр очрашканнар. Беләсеңме, нинди каты сугышлар булган монда! Ул заманнарда хан кылычларының сабын алтыннан коя торган булганнар. Шушы алтын кисәге әнә шул хан кылычының сабы иде инде. Менә тотып карале, күрәсеңме, тотарга нинди җайлы.

Әбәкер металл кисәген алып, авырлыгын чамалап карады.

– Алтын булмаса да, белә торган кешеләргә күрсәтергә кирәк, кызык өчен! – дип, әлеге әйберне кесәсенә салды. – Сабан өстеннән аны төшереп калдыруың бар. Миндә торсын.

– Ярый, алайса, – дидем мин.

Әбәкер, авыраеп киткән кесәсен сыйпаштыра-сыйпаштыра, тракторга таба атлады.

Кузгалып киттек. Мин табышымны укытучым Аллаяровка истәлеккә илтермен дип уйлана башладым. Аңарда андый әйберләр байтак җыелган инде. Әлбәттә, шушы табышка бәйләп, ул берәр кызык нәрсә сөйләми калмас.

Шуннан соң инде мин арый башладым, алтынны оныттым. Тракторның тигезле-тигезсез йөрүе тәмам хәлдән тайдырды. Әбәкер машинаны бик сәер йөртә: әле, нидер булган кебек, тракторны әкренәйтә, әле, моторны колак тондыргыч дәрәҗәдә үкертеп, капыл гына йолкып алып китә. Трактор торбасыннан бөркелеп кара төтен чыга да болганчык сөрем болыты булып басу өстенә җәелә, сабан, төрәннәр астына килеп тула иде.

Шул рәвешчә без кичкә хәтле эшләдек. Кояш баеса да, якты иде әле. Әбәкер кабина эченнән башын борып кына берничә тапкыр миңа күз салды, карашы әллә ничек сәер, тынычсыз иде. Ниһаять ул тракторны туктатты.

– Кил әле монда! – дип, миңа кул изәде.

Мин кабинага мендем. Әбәкернең чырае көл кебек агарган, үзе каушап калган шикелле, күзләре елт-елт йөреп тора иде. Ул, маңгаендагы тирләрен сөртә-сөртә, мотор тавышы аша әйтте:

– Кычкырырлык хәлем булмады. Син, бар, рычагларны ныгыт куй да, бераз үзең йөртерсең. Мин авырып торам, кәеф юк. Һавада йөрсәм, бәлки, бераз җиңеләеп китәр...

– Бар, бар! – дидем мин.

Мин сабан янына барып кире килгәндә, Әбәкер инде җиргә төшкән иде. Аның әллә ничек бөтенләй төсе киткән, алмаштырып куйган кебек иде. Ул, бөкрәя төшеп, бер сүз әйтми генә, читкә китеп барды.

«Авыруы каты, ахры. Эче авыртадыр, әнә ничек бөгелеп төшкән», – дип уйладым мин һәм тизләкне тоташтырып, тракторны кузгатып алып киттем.

Трактор тигез генә көчәнеп тартып китте. Менә ул тагын миңа буйсынды. Бу юлы да мин, машина йөртүнең бөтен кагыйдәсен төгәл үтәргә тырышып, дулкынлана башладым. Җир башына җиткәч, борылып кире киттем. Җир өстенә кичке эңгер караңгысы иңеп килә, салкын төшә башлаган иде. «Тагы ике әйләнәм, фараларны кабызырга кирәк», – дип уйландым, алдыма карап. Алда, сөзәк кашлак буйлап, кемдер тиз-тиз китеп бара иде, чокырга җитүгә, әлеге кеше аска төшеп, күздән югалды. Мин аның аркасын гына күреп калдым. Әбәкер иде ул. Ни булган аңа? Кая йөгерде ул? Берәр нәрсә күргәндер йә. Кыр уртасына җиткәч, мин кабинадан башымны чыгарып үрелебрәк карадым, ләкин Әбәкерне күрмәдем. Кая китеп югалды ул? Авыру ич үзе. Гаҗәп, мин, тракторны туктатып, моторны әкренрәк хәрәкәткә куйдым.

– Әбәке-ер! Әбәке-ер! – дип кычкырып карадым.

Ул җавап кайтармады. Шуннан соң мин, тавыш биргәне ишетелсен дип, моторны бөтенләй сүндердем.

– Әбәке-ер! Кайда син? Җавап бир! –дип кычкырдым, далага карап.

Әмма эңгер караңгысына күмелеп барган чокыр ярлары каршы җавап кайтармадылар.

Әгәр аның хәле бик начарланып киткән булса? Мин аны бөгәрләнеп җирдә яткан итеп күз алдыма китердем. Трактордан сикереп төштем дә шунда чаптым. Чокырның теге ягына чыктым, тирә-якка карандым. Беркем юк. Кашлак өстенә йөгереп менгәч, үзәнлек буйлап китеп барган Әбәкерне күрдем. Шактый ерак киткән иде инде ул.

– Әбәкер! Кая барасың? – дип кычкырдым, ләкин ул әйләнеп карамады, бераздан инде, кинәт җир упкан шикелле, бөтенләй күздән югалды.

Мин беравык басып тордым да кыяр-кыймас кына кире борылдым. Күктә тоныкбер тап төсле булып, соңгы шәфәкъ яктысы да сүнеп бара. Калкулыклар һәм үзәннәр өстенә моңсу караңгылык иңеп килә иде.

Нишләргә белмичә аптырап калган хәлдә кире кайттым. Бу моңсу аулак бер тынлык кинәт әллә нинди сәер булып тоелды. Гүяки дала минем аяк атлаганымны, ниләр уйлаганымны ишетеп-тыңлап тора сыман иде. Ә мин Әбәкер турында уйланып кайта идем. Бу җирләрдә чынлыкта ниләр булганын сөйләгән чакта, ул мине мыскыллап көлде, миңа ышанмады. Ә хәзер, әлеге алтын кисәгенә бәйләп үз хыялымнан өстәп тә сөйләгәч, тәмам башын-акылын җуйды... Юк, андыйлар башларын җуймыйлар! Ул аны инде күптән уйлап куйган булган, күрәсең, хәтта шул турыда сөйләнгәли дә иде, тик ул Сорокинны куркыткан шикелле генә эшли иде моны. Ул бит мондагы бөтен кешене дошман күрә иде, бөтенесе белән талашып, сугышып бетте. Ә Хәлифә? Әбәкернең бигрәк тә шуннан котыласы килгәндер. Ни шайтаныма кирәк Әбәкергә ул йөкле хатын? Шулай да получка алырга бер атна калганда качып китмәс иде әле. Ә болай аңа нәрсә — кичә генә шактый күп акча алды, акчасын беркайчан да тирмәдә калдырмый, үзе белән йөртә, димәк, ул бушка бик аз, бер генә көн эшләгән, өстәвенә әлеге табылдык әйбер алтын булып чыкса...

Хәлифә тавышына уйларым бүленеп калды:

– Әбәке-ер! Камил! Сез кайда? — дип кычкырды ул.

Хәлифә безгә, төнлә эшләү өчен, бидоннар белән су китергән иде.

– Кая китеп югалдыгыз? Куркып беттем. Көтәм-көтәм сезне, трактор тора, ә үзегез юк! – дип, Хәлифә борчылып каршы алды мине.

**(Ахыры 19 нчы биттә.)**

**«Сугышчан дан клубы» ассоциациясе рәисе Михаил Черепанов Татарстанда туган 219 якташыбызның Бөек Ватан сугышы барышында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителеп тә ул дәрәҗәдән мәхрүм калуын ачыклады. Алар арасыннан 67 се – татар, аларның 16 сы инде һәлак булганнан соң Герой исеменә тәкъдим ителгән, әмма алар батырлыгы орденнар белән генә бәяләнгән.**

# Герой исеменнән мәхрүм калган 7 татар

### Гәрәев Әгъләм Мифтах улы

Татарстанның Сарман районындагы Иләксаз авылында 1923 елда туган һәм шул ук район хәрби комиссариаты тарафыннан ил сагына чакырылган Гәрәев Әгъләм Мифтах улы Кызыл байраклы 310 нчы Новгород дивизиясенең 1084 нче укчы полкында укчы солдат булып хезмәт итә. Сугыш башында ук каһарманлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. «Хәтер» китабында һәм Россия Оборона министрлыгының сайтында ул бүгенге көнгә кадәр 1942 елның 25 августында Тверь өлкәсенең Зубцовск районында барган бәрелешләр вакытында хәбәрсез югалган, дип санала. Әмма Ә.Гәрәев улчак 180 нче укчы дивизия составында рядовой булып сугыша һәм яу барышында яралана. Ә госпитальдә дәваланганнан соң кабат хәрәкәттәге армияга кайта.

1945 елның 2 маенда Дивен елгасын ул көймә белән кичә һәм иң беренчеләрдән булып, дошман позициясенә ташлана. Әле суда чагында ук ул автоматыннан атып немец пулеметының расчетын юк итә, ә яр өстенә чыккач, гранаталар ташлап, дошманның бер тубын сафтан чыгара. Воллин каласын азат итү барышында да Ә.Гәрәев шәхси үрнәк күрсәтеп, үз рота сугышчыларын һөҗүмгә күтәрә. Шушы каһарманлыклары өчен 1945 елның 3 маенда Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә. Аны Кызыл байрак ордены белән бүләкләп кенә чикләнәләр. Ә.Гәрәев үзенең 1945 елда Герой исеменә тәкъдим ителгән икәнен дә белмичә, 2011 елның 5 августында вафат була.


Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество ГАРАЕВ Агляк Мифтахович
2. Звание красноармеец 3. Должность, часть Стрелок стрелковой роты 1084 стрелкового полка 310 стр. Новгородской Краснознаменной дивизии.
Представляется к присвоению звания " ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА ".
4. Год рождения 1923 г. 5. Национальность Татарин 6. Партийность б/п.
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне (где, когда) В Отеч. войне с 15.7.42 года Карельский фронт, с 24.2.45 года 2-й Белорусский фронт.
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне имеет три легких ранений, 23.8.42 г. 25.12.43 г. 12.10.44 год. - Карельский фронт.
9. С какого времени в Красной Армии с 15.5.42 года. 10. Каким РВК призван Сармановским РВК Татарской ССР.
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) ранее не награждался.
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

Красноармеец ГАРАЕВ 2 мая 1945 года при выполнении боевой задачи по форсированию пролива ДИВЕНОВ и в боях за город ВОЛЛИН проявил мужество и геройство. Тов. Гараев переправлялся через пролив на первой лодке. Быстрое течение воды и сильный ветер, а так-же беспрерывный обстрел со стороны противника создавали большую трудность переправы. Несмотря на это весь мокрый тов. Гараев умело управлял лодкой и в 20 м от берега по команде первым прыгнул в воду и устремился к берегу на врага. Будучи еще в воде он из своего автомата истребил пулеметный расчет немцев и выбравшись на берег забросал гранатами пушку немцев, стоящую на прямой наводке и мешавшей переправе.

В боях за город Воллин тов. Гараев шел в переди всех, своим личным примером воодушевлял остальных бойцов роты на выполнение боевого приказа.

За смелое и умелое форсирование широкого водного рубежа и за проявленное мужество и геройство, тов. Гараев достоин присвоения звания " ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА ".

... 1084 стрелкового полка подполковник / ... /

" 3 " мая 194[illegible]

### Габдрахманов Ибраһим

Ул Актаныш районының Түбән Гәрәй авылында 1906 елда туган, 1942 елның 1 гыйнварында фронтка озатылган. 247 нче Рославль дивизиясенең 916 нчы укчы полкында взвод командирының урынбасары булып хезмәт иткән. Өлкән сержант. Сугыш барышында 6 тапкыр яраланган, ике мәртәбә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән.

1945 елның 16 апрелендә И.Габдрахманов хезмәт иткән дивизия Германиянең Лебус шәһәре янынннан Берлинга таба һөҗүм башлый һәм 7 чакрым ара уза. Ибраһим үз взводы белән төнге караңгыда немецларның ут нокталарын урап уза да 20 дән артык гитлерчыны әсирлеккә төшерә. Рота командиры сафтан чыккач, Ибраһим аның вазифаларын да үз өстенә ала. Фашистларның бер-бер артлы оештырылган контрһөҗүмнәрен кире кайтарып, рота дошманның янә 65 сугышчысын юк итә. Ибраһим үзе яралланса да, сугышчан постын ташлап китми. 1945 елның 19 апрелендә И.Габдрахмановны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп, югарыга рапорт юллыйлар. Җиңү борын төбендә, татар булгач, хәтта каһарманлык та исәпкә алынмый. Ибраһимны да Кызыл байрак ордены белән генә бүләкләп чикләнәләр.


Наградной лист



(Дәвамы киләсе санда).

**Михаил ЧЕРЕПАНОВ.**
«Миллиард татар» челтәреннән.
**Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

● Л.Лерон белән Р.Галиуллин Мостафа авылы капкасы янында.

# ҖӘЛИЛ КЫЗЫ –

*Без «Мәдәни җомга»ның быелгы 3 февраль санында дөнья күргән «Җәлил кызы Люция» дип аталган язмабызда гыйнвар аенда Петербургка сәяхәт кылуыбыз һәм анда каһарман-шагыйрь Мусаның кызы белән күрешүебез хакында язган идек инде. Хәтерләүче булса, без анда Люция ханымның үз гомерендә бер тапкыр да әтисе Муса туган Мостафа авылы туфрагына аяк басмавы турында әйтеп салдык һәм, барча кыюлык-мәшәкатьне үз җилкәбезгә күтәреп, аны Оренбург өлкәсенә алып кайтырга вәгъдә биргән идек. Килешүләр байтак сузылса да, Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән, ниһаять, 30 сентябрь таңында без Люция ханым белән аның оныгы Баградны Оренбург аэропортында каршылау бәхетенә ирештек. Шулай итеп, Җәлил кызы Люция ханым 87 яшендә беренче мәртәбә Оренбург туфрагына аяк басты...*

Оренбургтагы барча җитәкчеләр безне колач җәеп каршылады, дисәк, нык күпертү булыр. Ни кызганыч, совет чорындагы идеология белән агуланган буынның күпчелеге әле һаман Муса Җәлилнең өч хатыннан өч баласы булуны кабул итә алмый, ә җитәкчеләрнең күпчелеге исә фәкать бер Әминә ханым нәселен генә күккә чөя. Исем-фамилияләрен тезеп чыкмасам да, Оренбургта да байтак урта кул җитәкчеләр безнең белән яки Люция ханым белән очрашудан төрле хәйлә табып качу ягын өстен күрде. Әле ярый, ике көн алда хакимият исеменә өч баш редактор исеменнән хат юллаган идек, шул тәэсир иткәнме, урынбасарларын булса да безнең янга юлларга җөрьәт иткәннәр бит...

Ул көнне Оренбургның Н.Крупская исемендәге үзәк китапханәсе Евразия төбәк тарихчыларының IX форумын үз залына туплаган иде. Кунакханәгә урнаштырганнан соң без Люция ханымны шунда алып киттек. Профессор Альберт Борһанов форумны ачып җибәрүгә үк сүзне Оренбург татарларының милли-мәдәни автономия рәисе Илдус Дәүләтовка бирде. Ә Илдус әфәнде кунакларны сәламләгәч тә, аларга Люция ханымны тәкъдим итте. Петербургта 18 ел буе якташлары белән бик сирәк күрешеп яшәсә дә, Люция апа бер генә «өлкән агай» сүзен дә кыстырмыйча, саф татар телендә ярып салды. Илдус әфәнде аңа чәчәк бәйләме бүләк итеп, иңнәренә ап-ак шәл салгач, Россиянең 8 өлкәсеннән килеп форумда катнашучы барча кунак Люция апаны аягурә басып алкышларга күмде. «Мине 1957 елда, әтигә Ленин премиясе бирелү уңаеннан Казан университетының актлар залында гына шулай алкышлаганнар иде», – дип пышылдады Люция апа тик бераздан гына. – «Башкача миңа андый олылау, хөрмәт күрү насыйп булмады шул».

Юлдаш язучылар – Ләбиб Лерон һәм Рөстәм Галиуллин исеменнән дә сәламләргә сүз бирелгәч, мин фәкыйрегез Люция апа язмышын урап үтә алмадым.

– Һәр бала турында «мәхәббәт җимеше», дип кабатларга үтә яратабыз. Люция апа да, Рауза Хисмәтуллинадан туган Альберт абый да – гыйшык җимешләре. Муса Җәлил, тәмам фронтка киткәнче, аларның берсеннән дә баш тартмаган. Инде Әминә белән кавышса да, Рауза белән Зәкия ханымнарга сагынулы, «сөеклем», дигән сүзләр белән тулы хатлар язып яткан. 1940 елга кадәр кача-поса Зәкия ханым янына килеп йөрүе дә, нәни Люцияне күкрәгенә кысып сөюе дә мәгълүм. Ходай Тәгалә дә Мусаның өч баласын бертигез, камил итеп яраткан. Аларның берсе һаман караңгыда калырга, икенчеләре фәкать мөнбәрләрдә генә ялтырап йөрергә тиеш түгел. Җебегән җитәкчеләр үзләренә Ходай Тәгалә сыйфатларын алудан арына белсә иде...

Форум үз эшен дәвам итте, ә безнең вакыт санаулы, Люция ханымны әтисе Муса эзләре белән таныштыру лазем. Фәннәр кандидаты Әлфия Габделхаликова һәм «Казан-тур» оешмасы җитәкчесе Раушания ханымнарны алып, Җәлил эзләреннән сәяхәткә чыктык. «Тупыллар» паркы каршындагы скверда Җәлил һәйкәле. Аның янына 15 февраль һәм 25 август көннәрендә 200 гә якын татар җыела, шунда Җәлил шигырьләрен укыйлар, чәчәк салалар икән. Зәвык белән эшләнгән, матур урын. Әмма Люция ханымның үз бәясе:

– Һәйкәлнең йөзе әтиемә бер дә охшамаган, аның урынына әллә монгол, әллә казах йөзе ясап куйганнар бит...

Муса 6 яшьтә чагында, әтисе белән килеп, Киров урамында, «Хөсәения» мәчетенең артындагы подвалда яши башлаган йорт янына килгәч, Люция байтак вакыт аңышмыйча торды. «Экскурсиячеләребез»: «Мостафа агай «Хөсәения» мәчете белән «Хөсәения» мәдрәсәсенә урам себерүче булып эшкә кергән, бәлки шуның өчендер, Мусаны да бер тиен түләүсез рәвештә шәкерт итеп укырга алганнар», – дип аңлаткач кына, хәйләлекнең сере аңлашылды.

Муса 1919 елга кадәр шушы мәдрәсәдә белем ала, аннары өяз комсомол комитетында эшләп йөри. 1921 елда бертуган абыйсы Ибраһим чибәр Зөбәйдәгә өйләнгән чагында, яшьләргә туйда менә мондый шигырь юллары язылган альбом бүләк итә:

*Түзә алмабыз, кара кан да коярбыз –*
*Басарбыз, киртәләргә бирмәбез юл.*
*Теләсәләр асарлар, без үләрбез,*
*Ләкин һичбер вакытта булмабыз кол...*

Бер гасырдан соң укып шаккатабыз: даһи Муса үз күңелендә гыйсъянлык, ихтилалазатлык, буйсынмас рухны яшүсмер чагында ук чыныктырган икән ләбаса...

Икенче көнне тулысынча Мостафа авылына бүләк иттек. Хуҗаларны алдан кисәткән идек, биредәге Җәлил музее мөдире Нәфисә ханым Гобәйдуллина, авыл старостасы, атаклы Рәмиевлар нәселеннән булган Ринат әфәнде, мәчет мәзине Ришат хәзрәт Сәгъдиев кына түгел, Шарлык районы башлыгының урынбасары Юрий Томин та каршы алды. Музейны карап чыккач, Җәлил бюстына чәчәкләр салдык та, авыл зиратына юл тоттык. Биредә Мусаның әнисе Рәхимә, әтисе Мостафа җирләнгән. Әтисе 1919 елда ук вафат булгангамы, кабер урыны төгәл билгеле түгел, әмма аны хатыны белән бергә җирләнгән, диләр, тик истәлек ташы юк, ваткаланып беткән. Рәхимә апаның кабере чардуган белән уратып алынган, уртада рәсеме куелган таш та тора. Аның янәшәсендә генә 1891 елда вафат булган Зөбәйдә Сәйфуллина кабере. Анысы – Рәхимә апаның газиз әнисе, Рәмиевлар нәселенең янә бер вәкиле ул!..

Люция апа шушы зираттан башлап тәмам шаккатырды. Ул зиратта әүвәл Рәхимә апа, Мостафа агай һәм аларның туганнары хакына Коръән сүрәсен яттан укып чыкты, ихлас дога кылды. Аннары авыл мәчетендә озаклап намаз кылды, янә сүрәләр укыды, догалар ирештерде. Без – юлчылар гына түгел, хәтта мәзин Ришат хәзрәт тә сүрә белән догаларның камиллегенә хәйран калды. Ә бер ай алдан гына Мәскәүдән муеннарына тавык тәпие таккан кунаклар кайткан булган, алары инде «Исәнмесез», дигән сүзне дә татар телендә әйтә алмыйча, шулай ук шаккатырган. Бер үк нәсел, әмма

● Без Х.Ямашев исемендәге китапханәдә.

● Оренбургтагы Җәлил һәйкәле янында.

● Люция ханым әтисенең бюсты янына чәчәк салган чакта.

# ӘТИСЕ ВАТАНЫНДА

капма-каршы иман... Гәрчә, куллар чаба-чаба, һаман каршылыйлар...

Мостафа тугызъеллык мәктәбендә үткән түгәрәк өстәл артындагы әңгәмә барышында да барча кунак, хәтта хакимиятнекеләр дә Люция апага гашыйк булып бетте. Аның интеллектуаль дәрәҗәсе буй җитмәстәй биек. Мәскәүдәге Кинематографлар институтында уку турында хәтта санаулы кешеләр дә хыяллана алмый. 1960 нчы еллар башы, экраннарда «Высота», «Три тополя на Плющихе», «Летят журавли», «Большая семья» кебек кинофильмнар пәйда булган замана. Ә Люция ханым «ВГИК» дип мәгълүм булган мәдәният институты студентлары белән төрле кичәләр әзерләшеп йөргән. Һәр кич саен диярлек яннарында йә режиссер Марлен Хуциев, йә Сергей Герасимов. Атна саен Анна Макарова, Владимир Высоцкий, Лариса Лужина, Олег Ефремов, Татьяна Доронина, Александр Баталов белән күрешүләр. Көлке түгел диген, атаклы Сергей Никоненко Люция туташ артыннан «Миңа кияүгә чыкмасаң, мәңге гафу итмим!» – дип кычкырып йөрсен әле!.. Әлбәттә инде, Люция дә алар янында чиксез канатланган, әллә нинди аллы-гөлле һәм өрфия болытлар өстендә йөзеп йөргән. Әмма шул 60 нчы еллардан соң Казанга әйләнеп кайткач, балалар бакчасына музыка буенча тәрбияче вазифасына да яллана алмыйча, әле Югары Совет рәисе С.Батыев, әле өлкә комитеты секретаре М.Вәлиев алдында йөз суы түгеп йөргән, ахыр чиктә инде мәдәният институтында аерым курслар уздырып, 16 ел буе 50 сумлык «хезмәт хакы» алган. Кемнәргәдер Җәлилнең 115 телгә тәрҗемә ителгән әсәрләре өчен каләм хакы аккан, алар мөнбәрдән төшүне белмәгән, ә каһарман Мусаның, Андре Тиммерманс бәяләвенчә, «копиядәй күчермәсе булган чибәр кызы» эт типкесендә яшәп җан асраган. Әле шул килеш тә, кайсы якка гына атласа да, «законсыз кыз», дип гайбәт чәйни-чәйни җанын ашаганнар. Аннары аның, тагын да түзәргә теләмичә, Питер каласына күчеп китүенә аптырарлыкмыни?! Аны хәтта бүген дә игътибар үзегенә алучы, ярдәм кулын сузучы сыңар гына җитәкче дә юк бит, барысы да үзе чәлеп өлгергән капчыгына капланып тик ятa...

Шул көнне кич төбәк тарихчыларының Евразия форумында катнашучы делегатлар Мостафа авылына да килеп җитте. Люция ханымны күргәч, һәркайсы аның белән бергә рәсемгә төшәргә йә җылы сүз әйтеп калырга ашыга. Люция апа һәммәсенә ачык вә мөлаем. Алар җиһанда Люция апа яшәвен, Җәлил данын үз төбәкләренә кайтып та таратырлар, бәлки. Дөресен танысак, Җәлил батырлыгын барча төбәк буенча бәян итү гомумән дә җитми. Менә шушы Мостафа авылына аяк басканчы ук, район үзәге булган Шарлык бистәсенә кереп чыктык. Анда Геройлар аллеясы ясап куелган. Районда туып-үскән ун каһарман бюстлары арасында өч татар вәкиле – бөек Җәлил, Нургали Галиев һәм Рамил Абдршин (?) сыннары да тезелешеп тора. Мусаны «ул Бөек Ватан сугышы чорында фашистларның үз өне Берлинда кабәхәт Гитлер режимына каршы көрәш алып барган, шуның өчен Плетцензее төрмәсендә җәзалап үтерелгән», дип тә, «ул «Моабит дәфтәрләре» өчен Ленин премиясенә лаек булган бердәнбер герой-шагыйрь», дип тә аерып куймаганнар. Җәлил хәтта туган туфрагында да рядовой герой гына.

Аннары Мостафада «СССРның халык артисты» дәрәҗәсенә ирешкән Хәлил Әбҗәлиловның бер генә төрле дә яктыртылмыйча «яшәве» бәгырьне телгәләде. Ярар, 2013 елда бирелгә Җәлил музееи Оренбург өлкәсе һәм Татарстан акчасы исәбенә яңартып чыктылар, аны ачуда бүгенге Рәисебез Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Тантанага мәдәният министры, күренекле әдипләр һәм артистлар да, сәнгать коллективлары да чакырылган иде. Ләкин нишләп аларның берсе дә Җәлил музее яки мәдәният йорты диварында Мусаның туганнан-туган абыйсы Хәлил Әбҗәлилов портреты яки исеме дә язып куелмавын искә алмаган соң? Бактың исә, алар – ике туган балалары. 1896 елда туган Хәлилнең 1903 елгы энекәше Ильяс хәтта бернинди үзгәрешсез көенчә Җәлилов фамилиясен алып яшәгән. Ә Хәлил, менә, әтисенең исеме Габделҗәлилне үз фамилиясе иткән. Ильяс белән Муса Мостафаның Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлары исемлегендә дә янәшә тора. Муса музееи безгә бизгән вакытта, аның бер диварына Мусага туганнан-туган абыйсы тиеш Хәлил Әбҗәлилов исемен язып һәм портретын элеп кую да артык булмас, нур өстенә нур булып торыр иде. Мәгәр юк бит, Мәскәүдән кайткан кунакларның берсе Хәлил аганың фотосын музейдан алдырып ташлаган. Аңа Рәсәйдәге кайсы гына оешма мондый башбаштаклыкка ирек биргәндер дә, кайсы оешма аның «түбәседер» – бөтенләй шыр-караңгы. Ленин премиясен бүлеп биргән чакта совет хөкүмәте Әминә белән Чулпан янәшәсендә Альберт белән Люция Җәлилләрне дә онытмаган, ә аннары тора-бара нинди юл белән бер генә гаилә барча дан һәм шөһрәткә хуҗа булып алган...

Янә Хәлил абый Әбҗәлилов хатирәсенә әйләнеп кайтмый булмый. Шуны онытмыйк без: татарлар арасыннан фәкать биш талант иясе генә «СССРның халык артисты» дәрәҗәсенә ия була алган. Фуат Халитов, Габдулла Шамуков, Марсель Сәлимҗанов, Шәүкәт Биктимеровларның берсен-бер онытмыйбыз. Барчасы да күңелгә якын, һәммәсе сагындыра. Алар янәшәсендә Хәлил ага бар. Мостафа авылы халкы, Шарлык районы гына түгел, барча Оренбург өлкәсе татарлары, безнең республикадагы мәдәният министрлыгы, Театр әһелләре берлеге, Бөтендөнья татар конгрессы, ахыр чиктә Г.Камал исемендәге академик театр коллективы – һәммәсе дә Мостафа авылы капкасы янында Хәлил Әбҗәлилов хөрмәтенә аерым стела куйдыру, Хәлил ага портретын һәм исемен Җәлил музеена кайтару, ул туган йорт нигезендә дә истәлек тактасы булдыру өчен көрәшергә тиеш. Әгәр безнең буын кайтарып өлгермәсә, аны яшьләр бөтенләй дә белми калу мөмкин. Без үткәнгә пистолеттан атсак, ул безгә туптан атып җавап кайтарачак. Туган телне болай да югалтабыз, асыл тарихтан да мәхрүм кала күрмик...

Ә Люция ханым, самолетка утыртып озатканда, шатлыгын һәм бәхетен яшерә алмыйча, без фәкыйрьләрегезгә рәхмәт укыйукый саубуллашты. Янә күрешкәнче...

**Вахит ИМАМОВ.**
Автор фотолары.

● Люция ханым һәм без Оренбургның Н.Крупская исемендәге үзәк китапханә баскычында. Уртада автономия рәисе И.Дәүләтов та бар.

***Пенза өлкәсендә 12 мәчетле, 10 мең татар яши торган Урта Әләзән авылы бар. Аны күпләр ишетеп беләдер. Казан хәбәрчеләре дә Урта Әләзән авылы белән танышып кайтты.***

# УРТА ӘЛӘЗӘННЕҢ

Урта Әләзән Казаннан якынча 500 км, ә Пензадан 90 км ераклыкта урнашкан. М5 трассасыннан тайпылгач, авылга нибары 10 километр барасы. Зур юлга якын булудан җирле халык оста файдалана. Бирердә сәүдә эше нык алга киткән.

Авылга кергәндә үк йөк машиналарының чамадан күп булуына игътибар иттек. Авыл башындагы автопаркта ватык «КамАЗ»лар сүтеп саталар. Анда тезелеп киткән Чаллы автопромы техникасын санап бетерерлек түгел. Аңа өстәп, Урта Әләзәндә шәхси машинасында йөк ташу белән шөгыльләнүчеләр күп, тонналап ит продукциясе җитештерелә, якында гына төзелеш материаллары заводы эшли. Боларның барысын татарлар булдырганын күрсәң дә, тагын бер кат милләтең белән горурланып куясың.

Сәфәребезнең беренче көнендә безне үз өенә кунарга авыл хуҗалыгы техникасын алып сату белән шөгыльләнүче Рәүф Бахтеев чакырды. Дөресрәге, безне монда Урта Әләзәннең 2нче мәчете имамы Рәфыйк хәзрәт Янгузаров алып килде. Хуҗага 40 яшьләр чамасы. Аның мәктәптә укучы 2 малае, 1 кызы бар. Ике катлы йорт төзегән, бүгенге көн күзлегеннән, яшәү өчен бөтен уңайлы шартларны булдырган.

Татарларда килгән кунакка табын әзерләп кую йоласы бар. Күркәм гамәл, чөнки өстәл артында уртак тел җиңелрәк табыла. Элек берәр якка җиргә кунакка барсак, өстәл янында «әле моны, әле тегене авыз итеп карагыз» дип, хуҗабикә йөгереп йөри торган иде. Монда Рәүфнең хатыны ризык әзерләү бүлмәсеннән чыкмады диярлек. Бирердә аш бүлмәсе аерым. Кайнар ашларны, чәйне Рәүф үзе китереп торды. Өйдә шундый тәртип: хатын-кыз, бала-чага таныш булмаган ир-ат кунакның күзенә күренмәскә тырыша.

Без йә Рәфыйк хәзрәттән, йә хуҗадан авыл турында сорашырга керештек. Авылда 12 мәчет эшли, 3 меңнән артык йорт, 10 мең кеше яши. Халык саны елдан-ел арта. Бирердә күп балалы гаиләләр – гадәти күренеш.

3 балалар бакчасы, 2 дәүләт мәктәбе, 1 хосусый мәктәп эшли. Соңгысында айлык түләү бәясе 6500 сум. Моңа 2 мәртәбә ашау, бөтен түгәрәкләр, өстәмә дәресләр кергән. Рәүф сүзләренчә, ремонтка, класс кирәк-яракларына аерым акча җыелар юк. Балалар иртәдән кичкә кадәр мәктәптә була. Алар, мәҗбүри программадан тыш, татар, гарәп телләрен укый, әхлак тәрбиясе ала. Баласын монда бирергә теләүчеләр күп, ләкин бөтенесенә дә урын җитми икән.

Урамда очраган бөтен хатын-кыз яулыктан иде. Авыл халкы тулысынча ислам дине кушканча яшиме, дип кызыксындык. «50 гә 50дер. Күп кеше яулыктан йөргәч, намазда булмаган хатын-кызлар да урамга яулык бәйләп чыга», – ди Рәфыйк хәзрәт Янгузаров.

Спиртлы эчемлекләр федераль челтәр кибетләрендә генә сатыла. Халык, җыелып, аларны яптырырга теләгән, ләкин кибет хуҗаларының аргументлары көчлерәк булган. Кибетләр аренда биналарында утыра. Аренда килешүе озак елларга төзелеп куелган, шуңа күрә бина хуҗасы «федераль челтәрләрне» куып чыгара алмаган. Урыннар бушаган очракта, авыл эшмәкәрләре хәләл ризык белән керергә теләгән. Эчүчеләр аз булгач, хәмердән әллә ни зур табыш юктыр, дип уйлыйк.

Ни өчен авылда җәмгатьчелек фикере белән исәпләшмичә хәмер сатуны оештыралар, дигән сорау туа. Җавабы бик гади булып чыкты. Аек тормыш алып барган, муллыкта яшәгән кешеләр белән идарә итү авыр. Аларны бер сынык икмәк яки бушлай концерт белән генә буйсындырып булмый. Кеше яхшырак яшәгән саен, киресенчә, хакимияттән яхшы әйләнә-тирә мохит, яхшы мәктәп, хастаханә һәм башкаларны таләп итә башлый. Шуңа күрә хакимияттә талантлы, белемле һәм булдыклы кешеләр утырырга тиеш. Түрәнең компетенциясе җитми икән, ул халыкның яхшы яшәвеннән курка, булдыклы кешеләргә аяк чала башлый.

● Сулдан уңга: Рәшит Куряев, Мөкаддәс Бибарсов, Илнур Миргалиев, Искәндәр Измайлов, Ислам Дашкин, Рифат Әбүзәров.

Шушы темага сөйләшеп утырганда, күз алдына бер сурәт килде. Бервакыт юлда барганда ашханәгә туктадым. Бусага янында бозау кадәр эт ята. Яшь кенә кызлар чыгалар да, эткә кайсы итле кабартма сыныгы, кайсы колбаса кисәге суза. Шуны гына көтеп яткан маэмай, боларның алларына килеп, арт аягына чүкте дә, кызларның кулларын ялый-ялый, ризыкны капты. Кызлар, шундый эт очравына сөенеп, тагын бер порция артыннан кереп китте. Бер сынык ипи өчен хуҗасының кулыннан үбеп, тез чүгеп яшәүче кешеләр азмы әллә? Наданлыктан һәм фәкыйрьлектән килә инде бу.

Урта Әләзән халкы бай яши. Моннан Мәскәүгә казылык, колбаса һәм башка ит продукцияләрен тонналап ташыйлар. Авылда 4 сугым цехы эшли. Шуларда көненә кимендә 300 баш эре терлек чалына. Авыл фермерларында 3 меңләп эре терлек асрала, ләкин ит эшкәртүчеләрнең ихтыяҗын ул гына тәэмин итә алмый. Малларны Пенза, Саратов өлкәләреннән, Кавказ республикаларыннан да ташыйлар. Көн саен фуралар белән маллар килеп тора, фуралар белән ит ризыклары китеп тора.

Урта Әләзән эшмәкәре Ильяс Дебердеев 4 ел элек Түбән Әләзән авылында төзелеш өчен коры катнашмалар җитештерә торган завод төзегән. Төзелеш кибетләрендә «Нью Микс» продукциясен күрсәгез, аны җитештерүче татар кешесе икәнен белеп торыгыз. Бирердә тәүлегенә 400-500 тонна продукция чыга. Ул ачылганнан бирле бер көн дә диярлек туктамый эшли. Йөзгә якын төрле коры катнашма Пенза өлкәсенә, Татарстан Республикасына озатыла.

Быел сәгатенә 10 тонна ком киптерә торган җиһаз алган булганнар. Ул күләм генә җитмәгәч, шушы арада сәгатенә 50 тонна киптерә торганын кайтартканнар. Үзләреннән арткан комны сатачаклар. Әлегә, җитмәгән күләмне Ульяновск өлкәсеннән ташыйлар.

Завод өчен 500 млн сум акча кертелгән. Хуҗа эшен банк кредитларсыз гына оештырып җибәргән.

Моның кадәр эш күләме булганда, авылда һәркемгә эш җитәрлек. Авылда эш юк, дип кайгырып йөрисе юк. Хезмәт урыннары җитәрлек булса да, читкә китүче яшьләр гел юк түгел икән. «Югары белем алып, Пенза, Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләрендә төпләнеп калучылар бар. Алар күбесенчә Урта Әләзән продукциясен сата торган, без-

● Урта Әләзәннең Җәмигъ мәчете.

# УҢЫШ СЕРЕ

● Урта Әләзәндәге шәхси йортлар.

нең эшмәкәрләр белән хезмәттәшлек итә торган оешмаларга урнаша», – ди Рәфыйк хәзрәт.

Урта Әләзәндә кызларны читкә кияүгә бирмәү традициясе турында ишеткән бар иде. Шул турыда сорамый кала алмадым. Элек, чыннан да, шулай булган, ләкин хәзер, кияү баерак булса, кәләшне чит авылга да, чит төбәккә дә чыгаралар. Соңгы елларда Югары Әләзәнлеләр белән кодалашу арткан.

12 мәчет, кибетләр тулы хәләл ризык, баланы мөселманча тәрбияләү, укыту мөмкинлеге, яулыктан йөрүгә кырын карамаулары мөселманнарга яшәргә уңайлы шартлар тудыра. Урта Әләзәндәге тәртипләргә кызыгып, чит төбәкләрдән, шул исәптән Татарстан һәм Башкортстаннан күченеп килүчеләр бар. Бервакыт авылда Урта Азиядән килгән кешеләр яшәп алган. Бераздан боларның тәртипсезлекләре күренә башлаган, һәм халык моңа озак түзмәгән – аларны авылдан куган.

Якын-тирә авыллар Урта Әләзәндәге мул тормышка кызыгып, көнләшеп яши. Авыл җирендә муллыкта яшәр өчен, көн саен бертуктаусыз тырышып эшләргә кирәк шул...

Икенче көнне без Городище районы мөхтәсибе, Урта Әләзән авылының Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Рифат хәзрәт Әбүзәров һәм Пензаның Хәбибҗамал Тенишева исемендәге мәдәни-агарту үзәге генераль директоры Рәшит хәзрәт Куряев белән бер машинада йөрдек. Мәчетләр, хосусый мәктәп, предприятиеләр белән таныштык. Хәзрәтләрнең дөньяга карашы, кайбер уй-фикерләре кызыклы.

1990 елларда, Урта Әләзәндә 3 мәчет эшләвенә карамастан, халыкның әхлак ягы аксады. Аракы эчүчеләр, зина кылучылар күп иде, – ди Рәшит хәзрәт Куряев. – Рифат хәзрәт Әбүзәров белән берничә яшь имам динне үстерергә тотынды да, кешеләр мәчетләргә, намазга тартылды, тәртип урнашты, Аллаһтан бәрәкәт килде. Урта Әләзәннең бүгенге халәте – ул 30 элек башлаган эшнең нәтиҗәсе.

Рифат хәзрәт Әбүзәров Урта Әләзәндә мәчет беркайчан да ябылмавын әйтте. Революциягә кадәр 5 мәчет, 2 мәдрәсә эшләгән. Советлар Союзы чорында шуларның берсе калган. Коммунистлар аны да ябарга җыенган, манарасын төшерергә хәтта солдатлар килгән, ләкин Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан фронтовиклар саклап калган. Халык мәчет каршына тере калкан булып баскан. «Шуннан соң, фронтовиклар җыелып, Мәскәүгә Калинин янына (автор иск.: Рифат хәзрәт кайсы Калинин икәнен төгәл әйтә алмады. Гражданнар сугышында катнашкан хәрби җитәкче, Пензадагы 19 бригада командиры Степан Калинин булырга мөмкин) барганнар. Калининнан хат килеп төшкәч, җирле коммунистлар мәчеткә кагылудан туктаган. Фронтовиклар арасында Калинин белән бергә армиядә хезмәт иткән бабайларыбыз булган», – ди Рифат хәзрәт Әбүзәров.

Татар милләте үсеше өчен милли хосусый балалар бакчалары, мәктәпләр ачарга кирәк, чөнки дәүләт оешмаларында милли тәрбия биреп булмый. Чит төбәкләрдә түгел, Казанда да татарча укытуны оештыруы кыен. Бер танышым татар бакчасында русча тәрбия бирүгә күчү тарихын сөйләгән иде. Шул искә төште. Татар төркемenә берничә башка милләт баласын керткәннәр дә, бераздан боларның ата-аналары Россиядә яшәвебезне, дәүләт теле – рус теле икәнен исбатлап, даулашып йөри башлаган. Конфликтның зурга китүеннән куркып, тәрбиячеләр рус теленә күчкән. Казанда татар телендә тәрбияне оештыра алмаган бакча мөдирләреннән дә шундый мисаллар ишеткәнем бар.

Хосусый милли мәктәп ачу – җиңел эш түгел, ләкин Урта Әләзәндә моны булдырганнар, һәм ул уңышлы гына эшләп килә.

– Хосусый мәктәп (репетицияләр үзәге) ачкач, төрле ведомстволардан бер-бер артлы тикшерүчеләр килде, аны ябарга теләделәр, – ди Рәшит хәзрәт Куряев. – Без адвокатлар ярдәмендә аларның карарларын судка биреп, эшчәнлекне саклап калдык. Монда йомшаклык күрсәтсәң, тиз басалар. Читтән караганда гына безнең эшләр бик җиңел барган кебек. Чынлыкта, уңышка ирешү өчен зур көч сарыф ителә. Ниндидер зур проект башлап җибәрү өчен эшмәкәрләр ярдәме, көчле юристлар, массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итү кирәк. Милли проектларның башында җәмәгать эшлеклеләре торса, әйбәтрәк, чөнки, эшмәкәрне төрле яклап кысарга мөмкиннәр, ә җәмәгать эшлеклесе ирекле, бәйсез була. Акчаны эшмәкәрләр бирергә тиеш. Акчаң булмаса, берни эшли алмыйсың.

**– Революциягә кадәр мәчет-мәдрәсәләрне, типографияләрне, газета-журналларны сәүдәгәрләр тоткан. Сез элеккеге күркәм традицияләргә кайтасыз кебек. Татарстандагы байларны ничек милли эшкә җәлеп итәргә икән?** – дип сорыйм.

– Зур проблема инде бу. Алар, димәк, милләткә файда китерүнең әһәмиятен аңламый. Аңлатырга кирәк, – ди Рәшит хәзрәт Куряев. – Кешене саранлык белән курку басса, ул кешелек сыйфатларын югалта. Андый кешеләр белән берни эшләп булмый. Әгәр без динебезне һәм милләтебезне сакларга телибез икән, без нәрсәне дә булса корбан итәргә тиеш – күпмедер малыбызнымы, вакытыбызнымы, җаныбызның бер өлешенме. Корбаннарсыз бернинди нәтиҗә булмый. Тарихка күз салсак, кешеләргә зур нигъмәтләр корбаннардан соң гына бирелә. Аллаһның иң якын кешесе – ул авырлыклар, сынаулар аша уңышка ирешкән бәндә. Куркаклык та саранлыктан килә. Кешедә шушы ике сыйфат һәрвакыт бергә йөри. Кеше саран икән, димәк, ул куркак. Куркак икән – ул саран була. Иманлы кеше Аллаһтан гына курка, һәм ул мохтаҗларга ярдәм итеп, байлыгын арттырганын, тормышына бәрәкәт өстәгәнен белә. Бәрәкәт телисез икән, халыкның иманы турында кайгыртыгыз...

Район хакимияте озак еллар Урта Әләзәндә көрәш, самбо түгәрәге ачарга рөхсәт бирмәгән. Авыл балалары йә Пензага, йә Кузнецк шәһәренә, йә Чаадаевка бистәсенә йөргән. «Күршедәге Чаадаевкада самбо түгәрәге бар, ә бездә юк иде. Дискриминация түгелме бу? – ди Рәшит хәзрәт Куряев. – Без, эшче төркем җыеп, район администрациясенә йөри торгач, Урта Әләзәннең 2 нче мәктәбендә самбо секциясе ачтылар. Хәзер бездә самбо да, бокс та, көрәш тә бар, Аллаһка шөкер».

Тормыш – ул көрәш. Күпләр балаларын сыйпап үстерәләр дә, аннары «ник тормышлары бармый икән» дип аптырыйлар. Көрәшеп үскән егетләр авырлыкларга тиз генә бирешми. Беркем дә безгә ризыкны китереп бирми, алдыбызга келәмнәр җәеп каршы алмый, бөтенесен үзебезгә булдырырга кирәк бит.

**Рифат КАЮМОВ.**
Автор фотолары.

# Күзәтү тәгәрмәче уйлап

**Куәтле пар двигательләре белән хәрәкәткә китерелүче, металлдан ясалган беренче күзәтү тәгәрмәчен америка инженеры, кайчандыр политехника институтын тәмамлап, төзүчелек белән бәйле белем-дәрәҗәгә ия булган һәм хәтта үз компаниясен дә ачып җибәрә алган Джордж Феррис уйлап тапкан. Дөрес, кешеләрнең аларны XVII гасырда ук кечкенә күләмдә, агачтан һәм кул көче кулланып әйләндерерлек итеп ясап караганнары булган инде. Мондый корылмалар, әйтик, шул гасырда Төркиядә дә кул көче белән әйләндерелгәннәр.**

XIX гасыр ахырында Чикагода узачак Технология казанышлары буенча бөтендөнья фестивале өчен кем нәрсә уйлап табар инде дип баш ватып йөргәндә, Д.Феррис күргәзмә комиссиясенә тәгәрмәч сызымын тәкъдим иткән. Моңа кадәр 1889 елда французлар Парижда үткән Халыкара фестиваль уңаеннан төзелгән Эйфель башнясын халыкка күрсәтүне һәркем истә тоткан чор бу. Манара авторы Г.Эйфель әлеге бәйгедә дә катнашырга теләп, шундый, тагын да биегрәк башня схемасын сызарга алынган. Әмма аның идеясы инде иске, кызыксыз дип табылган. Сүз уңаеннан, Эйфель күзәтү тәгәрмәчен уйлап табучыдан бәхетлерәк, уңышлырак иҗатчы булып чыккан, ул 1897 елда дәүләт һәм Париж муниципалитеты белән килешү төзегән, аның буенча башня 25 елга аңа шәхси кулланышка тапшырылырга тиеш булган. Аңа башня төзелешенең 25% чыгымын капларлык акча бүленгән. Калган сумманы каплар өчен акционерлык җәмгыяте төзелеп, кирәк сумма – 5 млн франкның яртысын Эйфель үзе, ә калган сумманы өч банк күтәргән. Бөтендөнья күргәзмәсе барышында чыгымнар тулысынча капланган, ә калган елларда башня уңышлы бизнес чыганагына әйләнгән.

Әйе, 1891 елда, бәйге башлангач та 33 яшьлек Д.Феррис бик биек тәгәрмәч төзергә планлаштырган. Ләкин күргәзмәнең баш архитекторы аның идеясын ошатмаган. Нечкә корыч таяклар белән ныгытылган эшләнмә аңа һич кенә дә ышанычлы булып тоелмаган. Ләкин үҗәт инженер баш архитекторның карары белән килешмичә, бихисап акчасын һәм күп заемнар җыеп, шушы конструкциянең ышанычлы булуын сынап карарга ният кылган. 1892 елда аңа шушы тәгәрмәчне ясый башларга ризалык бирелгән, ләкин, америкалылар французлар түгел шул, ул АКШ хөкүмәтенең матди булышлыгына таяна алмаган.

Тәгәрмәч өчен күп корыч тотылган, аны төрле җирләрдән китергәннәр. Тәгәрмәчнең диаметры – 75 м, авырлыгы – 2 000 тонна, ә аның 70 тонналык күчәре генә дә шул заманда ясалган иң зур коелма деталь буларак теркәлгән. Тәгәрмәчкә шул чактагы автобуслар зурлыгындагы 36 кабина беркетелгән һәм алар шулкадәр зур итеп, һәрберсенә 60 пассажир сыярлык итеп эшләнгән! 20 кеше утырып, 40 кеше басып менә алган. 20 минутлык тамашаны берьюлы 2160 пассажир күрә ала дигән сүз бу. 1893 елның июнендә Д.Феррис тәгәрмәче халыкка тәкъдим ителгән. Тик аның биеклеге 330 м биеклектәге Эйфель башнясына караганда дүрт тапкыр түбәнрәк булып килеп чыккан... Тәгәрмәчтә әйләнеп төшү өчен кешеләр 50 цент акча да түләгән. Ноябрь ахырына кадәр анда 1,5 млн кеше әйләнгән. Күргәзмәне оештыручыларны бу корылма бик баеткан. Тик инженерның үзе өчен генә әлеге тамаша күңелсезлекләр башы булып чыккан, чөнки күргәзмә ябылуга ук ул аны оештыручылардан акча сораган, ә алар Ферриска вәгъдә ителгәнчә түләмәгән. Заем биреп торучылар, инвесторлар шулай ук аның үзеннән акча таләп итә башлаган, судлашканнар. Ул зуррак күзәтү тәгәрмәчләре ясатып карау белән шөгыльләнсә дә, аларын да башкаларга сата алмаган. Шуннан соң Джордж үз компаниясенең бөлгә хакында игълан иткән. 1896 елда җәмәгате аннан аерылган, инженер эчә башлаган. Миллионнан артык инсанны шатландырырга өлгергән зат тәмам хәерчелеккә төшеп, берьялгызы калган. Һәм нибары 37 яшендә хастаханәдә корсак тифыннан үлеп тә киткән. 15 ай буе аның җәсәде көлен крематорийдан алырга теләүче табылмаган.

Ә менә аның тәгәрмәчен 1904 елга кадәр тагын ике тапкыр башка урынга күчергәннәр һәм Сент-Луиста бер ел эшләткәч, кискәләп-тураклап, юкка ла чыгарганнар. Феррис мондый күзәтү тәгәрмәчләренең һәр шәһәрдә диярлек төзеләчәген алдан белсә, билгеле, сөенер иде... Бу тамашаларны күрә алмаса да, аның исеме тарихта калган, чөнки АКШтагы мондый тәгәрмәчләрне бары тик Феррис тәгәрмәче дип атыйлар.

Феррис үлеменнән соң Венада аның проекты буенча, 30 кабиналы итеп төзелгән күзәтү тәгәрмәче (биеклеге – 64,75 м) – иң борынгылардан. Ул 1897 елда ук эшли башлаган. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында житди җимерелгән булса да, «Ризенрад» 1945 елда ук 15 кабиналы гына итеп яңадан торгызылган. Бу корылманы Англия Королева флоты инженер-лейтенанты У.Бассет төзеткән, ләкин аның да күзәтү тәгәрмәчләре бизнесы уңышлы бармаган, ул 1907 елда бөтенләй диярлек бөлеп, нибары 43 яшендә үлгән. 1906 елда тәгәрмәчне сүтәргә кирәк дигән карар чыккан, ләкин акча булмау сәбәпле ул сүтелмичә калган. Кинофильмнар төшергәндә аны кинокадрларга еш кертәләр. Ә менә 1914 елда биредә шаккатыргыч вакыйга булган: шушы тәгәрмәч кабиналарының берсенең түбәсенә менгән цирк артисты, француз ханымы атка атланган килеш тәгәрмәчтә тулы бер әйләнеш ясаган. 430 тонналык аттракцион 1985 елга кадәр дөньядагы иң зур тәгәрмәч булып та саналган әле, ул бүген дә Австрия күрке һәм... әле дә эшли.

Бөекбританиядә исә мондый корылма 1895 елда ике яшь австралияле инженерлар тарафыннан башкарылган. Алар аннан соң да дөнья буйлап тагын 200 гә якын тәгәрмәч төзегән. Лондондагы 94 м биеклектәге тәгәрмәч 1895 елдан алып 1906 елга кадәр эшләгән һәм анда 2,5 млн кеше әйләнгән.

Ә менә Темзаның көньяк ярына урнашкан «Лондон күзе» дип аталучы тәгәрмәч (135 м) нибары миллениум алдыннан 1999 елның 31 декабрендә ачылган. Аны бары тик 5 ел эшләтеп, сүтеп ташларга теләсәләр дә, тәгәрмәчнең популярлыгы арту сәбәпле ул әле дә әйләнә, каланы да кул учындагыдай итеп күрсәтә. Аңа башкала графлыгы районнары санына туры китерелеп 33 кабина беркетелгән, ләкин 12 нче кабинадан соң урнаштырылган кабинага... 14 саны сугылган. 13 нче кабина булмау – лондонлыларның бу саннан куркуын тагын бер кат раслый булыр... Әлеге тәгәрмәч биеклеге буенча дөньядагы алтынчы урында. Бер кабина-капсуланың авырлыгы – 10 тонна, ул уңайлы, үз күчәрендә әйләнә. Елына 3 млн. га якын кеше күтәрелгәнен исәпкә алганда, әлеге тәгәрмәч тә казнаны шактый баета.

АКШның кояшлы Лос-Анжелес шәһәрендәге, Санта-Моника пирсына урнаштырылган күзәтү тәгәрмәче исә – иң экономияле, ул 650 заманча типтагы Кояш батареяларын кулланып эшләүче дөньядагы бердәнбер аттракцион. Пристан 27,5 м. өстә. Төнлә



● Чикагодагы дөньяда иң беренче күзәтү тәгәрмәче.

● Кытайдагы Тяньцзинь күзе тәгәрмәче.

● Кытай. Бохай күзе.

# табылуга – 130 ел

● Ашхабад. Ябык күзәтү тәгәрмәче.



● Дубай күзе.

● Лос-Анжелес. Санта-Монико пирсы янындагы тәгәрмәч.

160 мең эконом лампа белән яктыртылып, онытылмас манзара хасил итә. Бу уникаль аттракцион автоном режимда эшли. Аны беркем дә әйләндереп тә җибәрми, беркем туктатмый да. Әгәр дә кайбер сирәк кенә көннәрдә болытлар хасил булса, аны да традицион энергия чыганагына тоташтыралар.

АКШның Лас-Вегасында, 2014 елда ачылган «Хай Роллер» тәгәрмәче (биеклеге – 167 м) ярты сәгать буе әйләнерлек итеп көйләнгән. Бер кабинага 40 кеше сыя, ләкин теләгәннәр биредәге берәр кабинада, билгеле инде, алдан килешеп, берәр тантана яисә туй да уздыра ала. Җирле халык әлеге аттракцион өчен нибары ярты бәя генә түли. Корылма тәгәрмәч – янәшәдәге казино милке. Франциядә төзелгән 60 м лы Roue de Paris мобиль тәгәрмәч сулы баклардан торучы балластлы. Шул сәбәпле аңа даими нигез таләп ителми. Ул инде Бирмингемда, Манчестерда һәм Амстердамда да булган.

Моңа кадәр иң биек тәгәрмәчләр Сингапурда һәм Кытайда иде. «Мәскәү кояшы»ның биеклеге 140 м булганга күрә, ул да Европадагы иң зур тәгәрмәчләрнең берсе һәм үз биеклеге буенча да дөньяда бишенче урынны яулап тора. Ерак Ашхабадтагы, тышкы диаметры 57 м ны тәшкил итүче корылма исә (биеклеге – 47,6 м) дөньядагы ябык типтагы иң зур тәгәрмәч буларак мәгълүм. Өстәвенә, ул хәйран матур итеп бизәлгән дә.

2008 елның мартында ачылган, 30 минут эчендә әйләнүче Сингапур тәгәрмәченең диаметры исә – 150 м, аның корпусы кибетләре, бар һәм ресторанналры булган 3 катлы терминал бинасына беркетеп куелган, аның капсула-кабинетлары био-бәдрәф, кондиционер белән җиһазландырылган. Билет бәясенә шампан шәрәбе, коктейль, җиңелчә ризык бәясе дә кертелгән. Әүвәлрәк тәгәрмәч бер якка таба әйләнгән. Ләкин фэн-шуй өлкәсе белгечләренең киңәшен тыңлап, 2008 елның августында ук аның әйләнү юнәлеше үзгәртелгән.

Иң моңсу, шыксыз тәгәрмәч Киев өлкәсенә караучы Чернобыль АЭСыннан 3 км ераклыктагы һәм калдырып кителгән Припять шәһәре паркында урнашкан, аны 1986 елның 1 маенда ачарга тиеш булганнар, әмма һәлакәт килеп чыгу сәбәпле ул ачылмаган.

Кытай һәм япон тәгәрмәчләрен дә искә алыйк. Мәсәлән, Кытайдагы диаметры – 110 м лы, биеклеге 120 м лы «Тяньцзинь күзе» Хайхэ елгасы аша салынган күпергә урнаштырылган дөньядагы бердәнбер күзәтү тәгәрмәче булып санала.

Ә Токио үзәгендәге зур һәм дөньядагы иң үзенчәлекле тәгәрмәчләрнең берсе – 80 м лы Big-O 2003 елда ачылды. Аның үзәк күчәре бөтенләй юк. Тәгәрмәченең уртасы буш. Моннан кала шушы бушлык аша бик тиз йөрүче «америка тауЧыклары» аттракцион рельслары сузылган һәм алар тәгәрмәч эченнән 130 км/сәгать тизлектә үтеп, кинәт кенә аска таба юл ала. Тәгәрмәчтә әйләнгәндә җыр сузырга теләүче японнар табылса, алар өчен кырык кабинаның сигезе караоке-машиналар белән дә җиһазландырылган.

Мондый күчәрсез тәгәрмәчләрнең берсе Кытайда да һәм ул да ис китәрлек зурлыкта: «Бохай күзе»нең биеклеге «Лондон күзе»ннән 10 м га артык – 145 м. Ул 4600 тонна авырлыкта, ә металл конструкциясенең нигезе «аждаһа сырты» дип аталучы үзара үзенчәлекле итеп бәйләнгән торбалардан ясалган.

Замананың иң биек күзәтү тәгәрмәче, билгеле, Дубайда. «Дубай күзе»нең биеклеге – 250 м! Ул 2021 елның көзендә ясалма утрауга урнаштырылды. Ул 48 кабиналы, аларның кайберләрендә бары да бар, хәтта кичке ашка заказ биреп була. Бу тәгәрмәчтә берьюлы 1750 кеше әйләнә ала. Бер әйләнеш 38 минутка тула. «Дубай күзе» тәүлек буе эшли.

**Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА**
әзерләде.

---

# Айга кырын карама

**Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!**

**21 октябрь (шимбә).** ***Рабигул ахир аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 15.17 сәгатьтә калка, 21.10 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.06 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җинел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь. Бу атнада күзне саклау мөһим.

## Эчәклекне чистарту (1)

Юан эчәклек ялкынсынуны (колит) болай дәвалап була. 1 стакан салкын суда 1 аш кашыгы бал эретәләр дә, көненә 3 тапкыр ашар алдыннан эчәләр. Дәва курсы – 1,5-2 ай. Бал тәэсирендә эчәклек патоген (авыру кузгатучы) микрофлорадан арына. Хроник энтероколит интектергәндә, 1 стакан суга 1 аш кашыгы алма серкәсе һәм 1 чәй кашыгы бал салып, көненә 3 тапкыр эчәләр. Дәва курсы – 1-1,5 ай. Елына шундый 3 курс үтәргә ярый.

**22 октябрь (якшәмбе).** ***Рабигул ахир аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 15.45 сәгатьтә калка, 22.47 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 10.01 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

## Эчәклекне чистарту (2)

Кич 1 стакан сөтне кайнатып, җылы урында 1 тәүлек төнәтәләр, аннары 1 аш кашыгы көнбагыш мае кушып болгатып, йоклар алдыннан эчәләр. Иртән ач карынга 1 кечкенә чөгендерне угычтан уып, тоз, сарымсак һәм көнбагыш мае кушып ашыйлар, яисә 1-2 алма ашап куялар. Иртән манный боткасы яки кәбестә салаты ашарга да була.

**23 октябрь (дүшәмбе).** ***Рабигул ахир аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 16.02 сәгатьтә калка, 0.28 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.57 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь.

**24 октябрь (сишәмбе).** ***Рабигул ахир аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 16.10 сәгатьтә калка, 2.05 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.53 сәгать.***

Үзгәрү, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына житкерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

## Алоэ сихәте

Эренле ангина, кариес, авыз куышлыгы ялкынсынуын алоэ дәвалый ала. 1 сантиметрдан артык булмаган алоэ яфрагын юып, кабыгыннан чистарталар, төнгелеккә

(Дәвамы 18 нче биттә).

## Айга кырын карама

яңак белән теш арасына кыстырып калдыралар. Ел буена шулай дәвалангында, микробларны үтерү сәләтенә ия алоэ аңкау бизләрендәге (гландалардагы), теш тишекләрендәге, авыз һәм борын куышлыгының лайлалы тышчасындагы бактерияләрне юкка чыгара.

**25 октябрь (чәршәмбе).** ***Рабигул ахир аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 16.24 сәгатьтә калка. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.48 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

### Ангинадан дәва

Эмальләнгән савытта 100 грамм бал һәм 1 аш кашыгы кура җиләге кайнатмасын, сүрән утта, болгата-болгата, кайнатып чыгара язалар (бал 60 градуста кайнап чыга), бераз суынгач, эчәләр, җылы юрганга төренеп яталар. Яисә 1 стакан уылган чөгендергә 1 аш кашыгы серкә салып, бераз төнәтәләр дә, сөзеп, тамакны чайкыйлар, 1 аш кашыгын эчәргә дә ярый. Болай хәтта хроник ангинаны да дәвалап була.

**26 октябрь (пәнҗешәмбе).** ***Рабигул ахир аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 16.32 сәгатьтә калка, 3.39 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.46 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

### Ютәлдән – хөрмә согы

Салкын тигәндә, ютәлләгәндә, өлгергән хөрмәнең согын сыгып, 3-5 аш кашыгы суга кушалар һәм авызны чайкыйлар. Ангина булганда, ярты стакан кайнаган җылы суга 2-3 тамчы ак чыршы мае тамызып, 3 тәүлек буе, көненә 3-4 тапкыр, авызны чайкыйлар. Салкын тия башлаганда, имбир тамыры турап салынган чәйне бал белән эчәләр, мондый эчемлек иммунитетны да ныгыта.

**27 октябрь (җомга).** ***Рабигул ахир аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 16.40 сәгатьтә калка, 5.11 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.39 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

### Корт кайнату

1 литр майлы сөт (озак сакланмый торган чын сөт кирәк), яртышар литр катык (яки майлы кефир) һәм 20 процентлы каймак, 1 стакан шикәр, 5 йомырка кирәк була (1 кг корт килеп чыга). Калын тышлы кәстрүлдә, иң яхшысы – казанда әзерләү яхшы. Йомыркаларны туглап күпертәләр, башка ингредиентларны кушалар да, уртача утта кайнатып чыгаралар. Төбенә ябышмасын өчен, беренче ярты сәгатьтә гел болгатып тору сорала. Кызарганчы, дымы парга әйләнеп беткәнче, әледәнәле болгаткалап, барлыгы 2,5-3 сәгать кайнатырга кирәк.

# Коръән ашы уздыру тәртибе

**Өйдә Коръән мәҗлесен уздырыру кирәкме? Табын нинди булырга тиеш? Сәдаканы тәлинкә белән җыеп алу рөхсәтме?.. Казанның «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы Нурулла хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН өйдә Коръән мәҗлесе уздыру тәртипләрен аңлата.**

Рамазан аенда елның-елында ифтар мәҗлесләре масштаблы күп урын ала башлады, аны мәчетләрдә үткәрү дә модага кереп китте. Дөресен әйткәндә, Совет чорларында, бәлки, аңа кадәрле дә, «халыкка мәчеттә авыз ачтыру» дигәнне без белмиишетми идек. Әлбәттә, аның уңайлы яклары бар: мәҗлес оештырырга теләгән кеше мәчеткә, мәсәлән, акчасын гына бирә, анда әзерлиләр, кешенең үзенең мәшәкате керми, кунакларны шунда гына чакыра да, килеп матур гына утыра да, рәхәтләнеп дога кылып китеп бара. Бер караганда, җайлы әйбер һәм мәчетләргә дә кулай.

Мәчеткә кеше килә, намаз укырга булмыйча, ашарга гына булса да, шунда дини сүз, Коръән сүзе ишетеп китә, шуңа үзенә күрә аның файдалы яклары бар. Әлбәттә, өйдәге мәҗлесләрне дә үткәрергә тырышырга кирәк – кафеда гына, мәчеттә генә түгел, чөнки өйдә үткәрелгән мәҗлеснең өстәмә саваплары була. Беренчедән, өйгә кунак керә. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм, өйгә кунак кермәгәндә, фәрештәләр дә керми, ди. Икенчедән, өйгә кунак кереп, өендә дога кылып китә. Бу инде – кунакның догасын алу дигән сүз. Шулай ук, өй эчендә Коръән укыла, шушында фәрештәләр килә, шушында бәрәкәт иңә, тынычлык иңә дигән сүз. Шуңа күрә шушы кешеләр белән кунак булу, алар белән бергә аралашу, утыру, аларны үз өеңә кертү – бу, үз чиратында, алар белән якынаю, араларны ныгыту дип атала. Шуның өчен дә кунакларны өйгә җыюны да онытмаска кирәк. Өйгә еллар буе кунак килмәгән очраклар булырга мөмкин.

Мәҗлесләрне ничек үткәрергә кирәк соң? Мәҗлесләр, әлбәттә, дини нигез белән үткәрелә, ягъни бисмилла әйтеп, Коръән белән башлана. Мондый мәҗлесләргә, әлбәттә, фәрештәләр килә, Аллаһ сүзе сөйләнгән очракта, Аллаһы Тәгалә шушында утырган кешеләрнең гөнаһларын кичерә, гафу итә.

Мәҗлес булгач, аның үз тәртипләре була. Мәҗлестә, әлбәттә, булырга тиеш хәләл ризыклар гына. Ягъни, динебез, шәригатебез буенча, безнең Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча рөхсәт ителгән хәләл ризыклар булырга тиеш. Менюны исә хуҗа үзе карый.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтә, әзерләгәндә бурычка кереп, үзегезгә авырлык китерерлек итеп әзерләмәгез, ди. Бездә – татарларда бит «узышып табын әзерләү» дигән «чир» бар. Берсеннән күреп чыгалар да, икенчесе дә куя башлый. Шуңа күрә хәзер безнең өстәлләребезгә елдан-ел төрледән-төрле ризыклар өстәлә бара. Мәсәлән, салатлар, ул берничә төрлегә әйләнде инде; тавык берничә төрле пешерелгән, кыздырылган; балыклар, шулай ук, берничә төрлеләр; бәлешләр әллә ничә төрлегә әйләнеп китте. Моның сәбәбе – бер-береңнән күреп, узышып эшләү. Ә күп очракта бу ризыкларның яртысы түгел, дүрттән бере дә ашалмый. Күбесе өстәлдә шул килеш калырга мөмкин. Һәм инде мәҗлес әзерләгән икенче кешегә бу – авырлык тудыра, чөнки кемдер күреп ала да, мин болай әзерли алмыйм, шуңа кунак чакырып тормыйм, әзерләнмим, дип әйтергә мөмкин. Менә шуңа күрә дә табынның байлыгын чамалап, үзеңнең хәлеңнән килгәнчә эшләргә кирәк.

Шулай ук, әгәр дә фәкыйрь кеше, мәҗлес үткәрәм, дисә, ризыклар күп төре булсын, дип тырышмасын. Булдыра алган кадәр эшләсен дә ихлас күңелдән кунакларын чакырсын. Иң мөһиме – аның чиста күңеле, нияте.

Мәҗлескә килгән вакытта, әлбәттә, кемдер күчтәнәч белән дә килергә мөмкин. Бу – күркәм гадәт, мәҗлескә килгән кешегә савабы да, бәрәкәте дә була. Кунак кешегә үзенең шушы күчтәнәчен табынга кую дигән гадәт бар. Бу шәригать буенча катгый әйтелгән сүз түгел. Әмма кеше үзе теләгән әйберне ала – күзе төшкән, ашыйсы килгән әйберне, шуңа күрә аның алдына үзенекен куйсаң, күңеле була, кунакның, шулай итеп, син күңелен күрәсең.

Табын артында утыруның үз тәртипләре бар. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм бисмилла әйтеп ашарга куша, алдыңдагыны гына ашарга, ди, тегендә-монда үрелеп утырмаска, ә инде төрле ризыклар төрле урынга куелган булса, үрелеп алудан да берниндй зыян юк.

Кыстауга килгәндә, безнең халкыбызда «әйдә-әйдә» дип кыстарга ярataлар. Кыстау – оялчан кешеләр килсә, бик күркәм әйбер. Әмма инде артыгы да кирәк түгел. Кайвакытта кеше уңайсызлана башлый. Тамак туйганнан соң ашарга ярамый безнең динебездә, кешене гонаһка кертергә мөмкинсең. Туйганнан соң ашау бу кеше өчен хәрәм булырга мөмкин.

Мәҗлес тәмам булгач, шушы ризыкны, күчтәнәч итеп, кунакларга бирееп җибәрәләр. Хәзер инде бәлешләрне махсус пластик тәлинкәләргә салып чыгаралар. Бу, шулай ук, күркәм гадәт, чөнки килгән кешегә, беренчедән, күңелле була; икенчедән, ризык күп калган очракта, аны ашап бетереп булмый, шуңа күрә аны кая куярга белмиләр, ризык ташланырга да мөмкин. Шуңа күрә, болай эшләү – шулай ук хәерле.

Ләкин хуҗа үзе күчтәнәчләрне бирмәсә, үзеңә табыннан нәрсәнедер җыеп китү кирәкмәс. Бу тәрбиясезлек булыр. Хуҗаның сездән соң да тагын кунаклар чакырган булуы мөмкин. Шуңа күрә хуҗа үзе бирмәсә, бу очракта алмау хәерле булыр.

Андый очраклар да бар: ифтар мәҗлесләренә кайбер апалар махсус сумкалар белән килә, төяп чыгып китәләр. Бу күренеш бик килешеп бетми аларга да, хуҗа алдында да матур түгел.

Коръән мәҗлесләрендә утыру тәртибе дә бар. Мөселманнарда ирләр белән хатын-кызларга бер табын артында утыру киңәш ителми. Бу гөнаһ булып санала. Шуңа күрә дә утырган вакытта ирләр – аерым табында, хатыннар – аерым табында. Әгәр дә инде хатын-кызларны җыярга туры килсә, аерым табында йә аерым бүлмәдә, йә аерым көннәрдә җыйсаң, хәерлерәк. Элек шулай булган. Ирләр табынында Коръәнне – мулла, хатын-кызлар табынында абыстайлар укыган. Безнең бит ирләр белән хатын-кызларның сөйләшү темалары да, кызыксынуларыбыз дә, үз-үзебезне тотышыбыз да аерылып тора. Шуңа күрә дә, аерым җыелышу бик яхшы бу очракта.

Киемгә килгәндә, ирләр шәригатькә туры килгәнчә киенә, ачык йөрмиләр. Хатын-кызларга килгәндә, проблема килеп туа. Күп очракта безнең хатын-кызларның итәкләре кыска була мәҗлестә. Тубыктан өстә икән – кыска дигән сүз инде ул. Шулай ук, куллары, муеннары ачык, яулыклары да баш очларына гына бәйләнгән яки чәчләре чыгарып бәйләнгән була. Гаурәтнең берәр җире ачык торса, бу мәҗлескә фәрештәләр килми. Алар ояла мондый мәҗлескә килергә. Фәрештәләр килмәгәч, без бик күп бәрәкәттән колак кагабыз. Шуның өчен дә, хатын-кызларга киенеп йөрү – бик кирәк әйбер.

Кайвакытта хатын-кызлар үтә күренмәле күлмәкләр дә киеп килә, бу очракта ул киенмәгән булып санала. Шуңа күрә дә хатын-кызларга киемгә игътибар итәргә кирәк.

Кайвакыт абыстайлар «тырнакларыгыз буялган» дип тә сүгәләр. Тырнак буяу – чынлап та мөселманнар гадәте түгел. Кайберәүләрнең фикеренчә, тырнакларны кайбер хатын-кызлар күрем вакытында кызылга буяганнар. Ягъни ирләренә хәбәр итәр өчен – артык сорау булмасынга эшләнгән әйбер. Бүгенге көндә тырнакларын кем тели – шул буяп йөри, алай гына түгел, тырнак өстенә әле ясалма тырнаклар да ябыштыралар. Болай итү безнең шәригать буенча катгый тыела. Бу кешеләрнең әлеге очракта тәһарәте дә дөрес булмый. Тырнакларны болай үстереп йөрү вәхшиләргә, хайваннарга охшау була, чөнки ерткыч хайваннарның тырнаклары озын. Алар шул рәвешле үзләренә корбан, ризык тота. Монда хатын-кызлар шуларга охшап кала. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм әйтә, озын тырнак астында шайтаннар яши, ди, тырнак озынрак булган саен, аның астында шайтаннар да күбрәк була. Кайвакытта «юкка бәйләнәләр» дип, абыстайлардан зарланалар, әмма бу – алар уйлап чыгарган әйбер түгел. Әмма аның үзенең таләпләре бар. Мәҗлескә килгәндә, син, әлбәттә, тырнакны өзеп ташламыйсың, ләкин абыстай әйтеп куйса, аңа ачуланмаска кирәк. Бу инде мөселман кешесенә туры килә торган әйбер түгел.

Һәрбер нәрсәнең үз вакыты була. Мәҗлеснең вакытын чамаларга кирәк – көн-төн утырып булмый. Үз вакытында китә дә белергә кирәк, чөнки хуҗа инде, ярар, китегез, дип куып чыгара алмый. Шуңа күрә, матур гына итеп, вакыты җиткәч китеп бару – әдәп-тәртипкә керә торган гадәт.

Инде сәдакага килгәндә, күп мәҗлесләрдә сәдака тараталар. Кайбер абыстайлар, сәдака таратырга кирәк түгел, бу – дөрес түгел, дип тавыш чыгара. Беренчедән, сәдака биргән кешегә беркайчан да каршы төшәргә кирәкми. Кешенең күңелендә бирү теләге бар икән, ничек инде син аңа «бирмә» дип әйтә аласың? Килер бер көн, син тартып та ала алмассың ул кешеләрдән. Шуңа үзләре бирәләр икән, алырга кирәк.

Кайберәүләр «мин сәдакага мохтаҗ түгел», ди. Мохтаҗ түгелсең икән, тавышланма, ал да башка кешегә бүләк итеп бир. Янында утырадыр мохтаҗы, күршең бардыр мохтаҗ, юк икән, мәчеткә алып бир. Кайбер урыннарда сәдакаларны тәлинкәләргә җыялар, аннан соң яки хуҗага, яки мәчеткә бирәләр. Бу да шәригатькә каршы килә торган әйбер түгел, кулдан кулга таратып йөргәнче, шул тәртиптә сәдакаларны бирергә була.

«Сәдаканы күпме бирергә?» – дигән сүз дә бар. Мөмкинчелеккә карап бирелә. Монда инде «энә дә – бүләк, дөя дә – бүләк» дигән сүз бар. Ләкин «энә дә – бүләк» – бу фәкыйрьләр өчен. Фәкыйрь кеше, «әз бит, әз» дип, бирергә оялмасын, чөнки аның мөмкинчелеге шулай. Ә бай кеше әз бирүдән оялсын. Чөнки бай кешенең мөмкинчелеге күбрәк. Күбрәк бирсә, аңа савабы да зуррак була, дөресрәк тә була бу сәдака. Шуңа күрә, «энә дә – бүләк, дөя дә – бүләк» дигән сүздән, энә – фәкыйрьләр өчен, ә дөяне бирергә тиеш байлар. Менә шулай аның күләмнәре.

Әлбәттә, сәдаканы сорап алмыйлар, кемдер бирми икән – ул аның үз эше. Инде сәдака тараттылар икән, өстәмә бәрәкәт, өстәмә дога кылына шушы сәдакаларга. Менә мәҗлесләребезнең тәртибе, кыскача гына, шундый.

**Фагыйлә ШАКИРОВА,** блогер.

# Татар җайдаклары Европада

**(Дәвамы. Башы 38, 39, 40 нчы саннарда).**

91. «Башкорт» Гайнулла Килдеяров – 28 яшь, Зәбәер авылыннан (Актаныш). 1814 елда армияда.

92. «Башкорт» Гайнулла Тукаев – 29 яшьтә, Зәбәердән. 1814 елда армияда.

**Унсигезенче йорт:**

93. Старшина ярдәмчесе Ибраһим Айдагол улы Морзакаев – 22 яшьтә, Айман авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

94. Зауряд-йөзбашы Габделсалих Габделмән улы Дускәев – 29 яшьтә, Мөшегә авылыннан (Минзәлә). 1812-1814 елларда 5 нче полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

95. «Башкорт» Фәйзулла Ильясов –30 яшь, Мөшегәдән. 1812 елда армияда.

96. «Башкорт» Корыч Дусаев – 28 яшь, Мөшегәдән. 1814 елда армияда.

97. «Башкорт» Ибраһим Искәндәров – 29 яшь, Чүплек (Кызыл төбәк) авылыннан (Минзәлә). 1812 елда армияда була.

● **«Башкортлар» Франциядә.** 1814 ел. Б.П. Виллевальде эше.

98. «Башкорт» Габделкадыйр Габитов – 28 яшь, Айманнан (Актаныш). 1812 елда армияда.

99. «Башкорт» Сәйфетдин Мөхәммәтрәхимов – 27 яшь, Айманнан. 1812 елда армияда.

100. «Башкорт» Нигъмәтулла Габдрәшитов – 27 яшь, Бүләр авылыннан (Мөслим). 1813 елда армияда була.

**Унтугызынчы йорт:**

101. Урядник Нәҗметдин Шамкаев – 19 яшьтә, Кормаш авылыннан (Сарман). 1812-1814 елларда 6 нчы «башкорт» полкы составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

102. «Башкорт» Габделлатыйф Таипов – 31 яшь, Имән авылыннан (Сарман). 1812 елда армияда була.

103. «Башкорт» Габдерәфыйк Габдерәзәков – 29 яшь, Имәннән. 1812 елда армияда.

104. «Башкорт» Габделхалик Габделсәламов – 30 яшьтә, Шарләрәмә авылыннан (Сарман). 1814 елда армияда.

105. «Башкорт» Шәехсәгъди Мөхәммәтрәхимов – 29 яшь, Шарларәмәдән. 1814 елда армияда.

106. «Башкорт» Гыйбадулла Корбангалин – 23 яшь, Шарларәмәдән. 1814 елда армияда.

107. «Башкорт» Шаһиәхмәт Мансуров – 29 яшь, Кормаштан. 1814 елда армияда.

**Егерменче йорт:**

108. Урядник Мәүликәй Ишморатов – 23 яшьтә, Тугаш авылыннан (Мөслим). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

109. «Башкорт» Тимеркәй Кутыев – 33 яшь, Югары Табын авылыннан (Мөслим). 1812 елда армияда була.

110. «Башкорт» Габделхалик Габделкәримов – 31 яшь, Саклаубаш авылыннан (Сарман). 1812 елда армияда.

111. «Башкорт» Гайнулла Гобәйдуллин – 31 яшь, Саклаубаштан. 1812 елда армияда.

112. «Башкорт» Габделханнан Исмәгыйлов – 27 яшь, Саклаубаштан. 1812 елда армияда.

113. «Башкорт» Гыйсмәтулла Фәтхуллин – 23 яшь, Сөлек авылыннан (Сарман). 1814 елда армияда.

114. «Башкорт» Муса Габделсәламов – 34 яшь, Чураш авылыннан (Сарман). 1812 елда армияда.

**21 нче йорт:**

115. Урядник Габделнасыйр Әбҗәлилов – 22 яшьтә, Күбәк авылыннан (Мөслим). 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

116. Зауряд-йөзбашы Ярмөхәммәт Әлмөхәммәт улы Ибраев – 39 яшь, Метрәй авылыннан (Мөслим). 1806-1807 елларда 3 нче «башкорт» полкы составында Пруссия кампаниясендә катнаша (Ә.Әсфәндияров, 532 б.).

117. «Башкорт» Габделхәким Яһүдин – 33 яшь, Сасыборын авылыннан (Мөслим). 1812 елда армияда була.

118. «Башкорт» Габделвахит Габдиев – 33 яшь, Сөякәй авылыннан (Мөслим). 1812 елда армиядә.

**22 нче йорт:**

119. Зауряд-йөзбашы Габделгаффар Габделсәлам улы Ишмәтев – 21 яшь, Яңа Әлем авылыннан (Актаныш). 1807 елда 20 нче «башкорт» полкы, 1812-1814 елларда 6 нчы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була (Ә.Әсфәндияров, 269 б.).

120. Зауряд-йөзбашы Вәлиша Шәрип улы Шәйдәков – Яңа Әлемнән. 1812 елда 20 нче «башкорт» полкы составында походларда була (Ә.Әсфәндияров, 269 б.).

121. «Башкорт» Хазбулат Сәлимҗанов – 31 яшь, Аеш авылыннан (Актаныш). 1812 елда армияда була.

122. «Башкорт» Гыйсмәтулла Бикташев – 28 яшь, Аештан. 1813 елда армияда.

123. «Башкорт» Фарукша Арсланов – 30 яшьтә, Яңа Әлемнән. 1812 елда армияда.

124. «Башкорт» Мәндикәй Әбсалихов – 30 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армияда.

125. «Башкорт» Ярмөхәммәт Рапталов – 30 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армияда.

126. «Башкорт» Габделсаттар Әбҗәлилов – 24 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армияда.

127. «Башкорт» Исхак Габделсалихов – 23 яшь, Яңа Әлемнән. 1812 елда армияда.

128. «Башкорт» Иләмән Вәлитов – 30 яшь, Иске Әлемнән. 1812 елда армияда.

129. «Башкорт» Ибраһим Тойгынов – 31 яшь, Аккүз авылыннан (Актаныш). 1812 елда армияда.

**23 нче йорт:**

130. Зауряд-йөзбашы Шәмсетдин Исмәгыйл улы Госманов – 30 яшь, Бәзәкә авылыннан (Менделеев районы). 1812-1814 елларда 6 нчы атлы полк составында төп армияда һәм чит илләргә походларда була (Ә.Әсфәндияров, 51 бит).

**24 нче йорт** буенча мәгълүмат юк.

**25 нче йорт:**

131. Зауряд-есаул Габделлатыйф Карабай улы Тутаев – 31 яшьтә, Исәнбай авылыннан (Әгерҗе). 1807 елда 3 нче «башкорт» полкы белән яуларда катнаша, 1812-1814 елларда 6 нчы атлы полк составында төп армияда һәм чит илләрдә походларда була (Әсфәндияров, 42 б.).

132. Зауряд-есаул Габделнасыйр Зәйсән улы Имамматев – 30 яшь, Теләкәй авылыннан (Актаныш). 1812-1814 елларда 6 нчы полк белән төп армияда һәм чит илләргә походларда була.

133. «Башкорт» Габделҗәлил Гайсин – 30 яшь, Үтәгән авылыннан (Әгерҗе). 1814 елда армияда була.

**Вахит ИМАМОВ.**

**Файдаланылган әдәбият:**

А.Асфандияров. Аулы Мензелинских башкир. Уфа, 2012.
З.Гатиатуллин. Мензелинцы в Отечественной войне 1812 года.
Т.Кәримов.Йәнәй волосте.Кульъязма китап.

## Дөя күзе

**(Ахыры. Башы 10 нчы биттә.)**

Ни дип җавап бирим инде аңа? Дөресен әйтеп бирдем:

– Әбәкер китте. Эшен ташлап китте, – дидем.

– Ә... ник... ни өчен? – дип сорады Хәлифә, тотлыга-тотлыга.

– Белмим.

Алтын турында әйтмәдем, Әбәкер өчен уңайсызландым.

– Китте, алайса? – Шулай дигәч, Хәлифә беравык сүзсез торды, аннары арбадан бидонны йолкып алды да дөңк иттереп җиргә утыртты. Нәрсә дияргә дә белмәгән кебек: –Ник ташыйм соң әле мин бу суны? – дип сөйләнде.

Мин бидонны радиатор янына алып киттем, ә Хәлифә йөзе белән кабинага капланды да елап җибәрде.

Мин аптырап калдым. Аны ни дип юатырга да белмәдем. Хәлифәгә таба борылып:

– Бәлки, кире кайтыр, – дигән булдым.

Ул, үкси-үкси:

– Аның өчен түгел лә, – диде дә яшьле күзләре белән ялт кына миңа таба борылды. – Ышанган булдым бит, хыялланган булдым! Нәрсәгә ышандым? Нәрсә дип хыялландым? – дип, Хәлифә кинәт чыңлап торган бер көч белән иңрәп кычкырып җибәрде, хәтта буп-буш дала да ыңгырашкан бер аваз белән аңа җавап кайтарды. – Бик тырыш, эшчән егет, мәйтәм, усаллыгы бетәр. Яхшылык белән, мәхәббәтем белән җанын эретмәкче булдым. Ә ул? Әй, сөйләп торасы да юк... Әнә ат эшли, тик кеше кеше инде, иң элек аның җаны булырга тиеш. Шул чагында, эш ул – бәхет, шул чагында эшләвеңнең дә мәгънәсе бар... Ә ул, ул берни аңламады. Нинди булса, шулай китеп тә барды. Гарьлек миңа, һай, белсәгез иде, гарьлек!

Мин, Хәлифәнең авыр кичерешләренә бирелеп, бер сүз әйтә алмыйча тик тордым. Бик кызгандым аны, аның өчен йөрәгем әрнеде. Хәлифәнең ничек итеп шундый кешене ярата алуын аңламадым... Әбәкер Хәлифәдән китеп, бүген үзенең нинди бәхетен югалтканын белсә, аңласа, Хәлифә елау түгел, ул үзе кышкы ачы салкындагы бүре урынына улар иде.

Хәлифә атына утырды да бер сүз дәшми китеп барды.

Анархай даласы тын гына, тыныч кына йоклап ята.

Кайдандыр бик ерактан, әрем сабаклары өстеннән тирбәлеп тарала-тарала, уйсулыклар буйлап зәгыйфь кенә паровоз тавышы килеп ишетелде. Әбәкер инде, бәлки, товар вагонына ябышып китеп тә баргандыр?.. Бар, кит, кабәхәт җан, юлыңда бул! Анархай синсез дә яшәр, синнән башка да эшли белербез...

Шуннан соң минем аны исемә дә төшерәсем килмәде. Эшкә тотынырга вакыт иде. Мин кабыза алмыйча байтак азапланганнан соң гына, трактор, төн караңгысын өркетеп, гөрелдәп эшли башлады. Кабинага менеп утырдым да фараларны кабыздым.

Хәзер инде мин бөтенесе өчен җавап бирәм. Шунда «их, янымда теге, маңгаенда чәч чугы йөрткән сөйкемле кыз булса икән, шушы кыргый әрем даласында гүзәл Анархай иле булачагына ул да ышансын икән» дип теләдем.

**1960.**

## Тыйнак миллиардерлар да бар

Тыйнак миллиардерлар турында сүз чыкса, “Forbs” рейтингы лидерлары Безос, Баффетт һәм Цукерберг искә төшә, тик нигәдер Россиядәге олигархларның исемнәре бер дә телгә килми. Аларның барысының да максаты кыйбатлы яхта, антиквариат тупланмасы, зиннәтле виллалар гына микәнни? Юк, россияле байлар арасында да тыйнак һәм кешелеклеләре шактый икән. Мәсәлән, Девид Ян – ABBYY компаниясен оештыручы, беренче электрон сүзлек төзүче, 700 миллион долларлык мөлкәт хуҗасы. Һәрвакыт гап-гади күлмәк киеп йөрүче бу эшкуар, бәхет байлыкта түгел, дип саный. Аңарда математик прагматиклыгы һәм фәлсәфәче хыялыйлыгы яраша. Ян бөтен бизнесын йөрәге аша үткәрә, һәр эшенә башыннан чума, бар нәрсәне вак-төягенә кадәр тәфсилләп өйрәнә. Бөтен дөньяга мәгълүм текстларны тану программасын төзүче данлыклы айтишник, туклануның сәламәтлеккә һәм аңга тәэсирен аңлау өчен, берникадәр вакыт ач торган, ресторан ачар алдыннан исә үзе каһвә пешерергә өйрәнгән, махсус курслар үткән. Хәзер ул ясалма интеллектлы, дөньяда иң акыллы йорт төзү белән мәшгуль, әмма моның белән мактаныр өчен түгел, бәлки социаль эксперимент кысаларында шөгыльләнә. Владимир Мельников – “Gloria Jeans” җитештерүен һәм кибетләр челтәрен оештыручы, 700 миллион долларлык мөлкәт хуҗасы. Ул өч тапкыр төрмәдә утырган, 10 ел гомерен рәшәткә артында үткәргәч, нәтиҗә ясап, дингә килгән. Фәкыйрьләргә ярдәм итү өчен хәйрия фонды булдырган, кыен хәлдә калучылар өчен реабилитация үзәге төзеткән һәм карап тота, бөтен байлыгын хәерчеләргә тарату турында хыяллана. Быел җәй үзенең “Gloria Jeans” компаниясендә 10 елдан артыграк эшләгән 2527 хезмәткәренең һәркайсына 1әр миллион сум акча биргән. Роман Авдеев – Мәскәү кредит банкы хуҗаларыннан берсе, 750 миллион долларлык мөлкәте бар. Тормышта тәп эше – хәйриячелек һәм гаилә. Ул акчасын 23 баласын (шулардан 17 се – асрамага алган) тәрбияләүгә тота. Ресторан урынына пиццериядә туклануны артыграк күрә, ял көннәрендә кулына балта алып агач юна, метрода йөрергә ярата. Балаларының һәркайсына машина һәм торак калдырачак, әмма шуннан артык бернәрсә дә васыять итмәячәк. Ятимнәргә булышу өчен “Игелек арифметикасы” фондын оештырган. Евгений Касперский – “Касперский лабораториясен” оештыручы, 1,3 миллиард долларлык мөлкәт хуҗасы. Эшкуарның бернинди брендларга да исе китми, ул бик гади киенә һәм гел вулканнар янына сәяхәт итә: Камчатка, Алтай, Курил, Якутия, Гренландия, Антарктидада төшергән искиткеч  пейзаж фотоларын социаль челтәрдәге сәхифәсенә куеп бара. Компаниясе, Мәскәүдәге фатиры һәм BMW машинасыннан кала бернәрсәсе дә юк. Татьяна Бакальчук – Wildberris интернет-кибете хуҗасы, 8 миллиард долларлык мөлкәте бар. Татьяна – Россиянең иң бай хатын-кызы,  әмма зур акча эшкуарның тормышка карашын үзгәртмәгән. Интроверт булганга, аңа бу популярлык белән килешүе бик кыен, ул үзе турында сөйләргә яратмый. Мәскәүдә фатиры һәм ике машинасы бар, тик Бакальчук үзенең җиде баласын иң зур байлыкка саный, гардеробындагы иң кыйммәтле әйбер – Prada сумкасын да аңа дуслары бүләк иткән.

**(“Forbes.ru”).**

## Иң озын койма

Җиһандагы иң озын койма Австралиядә урнашкан, аның озынлыгы 5614 чакрым тәшкил итә. Бередә XIX гасырда сарык үрчетү алга киткән, икътисадның мөһим тармагы булган. Әмма көтүчеләргә кыргый Динго этләре бер дә тынгы бирмәгән. Аларны капкын куеп та тотканнар, агулаганнар да, атканнар да, әмма бернәрсә дә ярдәм итмәгән. Шунлыктан 1880 елларда гаять зур тимер челтәр койма төзи башлаганнар, ул Квинслендның көньягындагы сарык көтүлекләрен кыргый этләрдән һәм бик күп үрчегән куяннардан сакларга тиеш булган. “Бөек Австралия дивары” 1885 елда төзелеп беткән. 1960 елларда койманың аерым секцияләре барысы бергә берләштерелгән. Тувумба шәһәреннән Зур Австралия култыгына кадәр сузылган дивар илнең корылыклы төньяк-көнбатыш өлешен чагыштырмача уңдырышлы көньяк-көнчыгыштан аерып тора. Аны карап тоту дәүләткә елына 15 миллион Австралия долларына төшә. Янында һәрвакыт патруль йөри, алар челтәрне ямыйлар, куяннар казыган җир асты юлларын күмәләр, бирге якка чыккан кыргый этләрне үтерәләр.

**(“Batona.net”).**

## Балык көне

СССРда халык сәламәтлеген кайгырткannar, дип сөйләргә яратсалар да, балык көне кертелү бер дә моңа бәйле түгел. 1930 еллардагы күмәкләштерү сәясәте нәтиҗәсендә илдә дуңгыз үрчетүчеләр кими, ит кытлыгы сизелә башлый. 1932 елның 12 сентябрендә тәэминат буенча халык комиссары Анастас Микоян ит кытлыгын балык хисабына бетерү турында фәрман имзалый, чөнки елга-күл-диңгезләрдә ул әле бихисап була: барлык ашханәләрдә балык көне кертелә – пәнҗешәмбе халыкны хек һәм мойва белән сыйлый башлыйлар. Моңа күнегү авыр була, бигрәк тә Кавказда ит ашап үскән Микоян үзе интегә. Әмма тора-бара ияләшәләр.

**(“Мир новостей”).**



## Помидор агачы

***Спрут F1 помидор агачы – моннан берничә ел элек чыгарылган гибрид томат сорты, ул фермер һәм яшелчәчеләрдә гаять зур кызыксыну уята. Гадәти булмаган үсемлекнең биеклеге 4 метрга, ябалдашының мәйданы исә 40-50 квадрат метрга җитәргә мөмкин. Ул 1-1,5 ел үсә һәм гомуми авырлыгы 1,5 тоннага тәңгәл 14меңләп томат бирергә сәләтле. Помидор агачы үзе өчен махсус төзелгән теплица каркасын сигезаяк кебек чорнап ала. Аның тамыр системасы бик куәтле. Әлеге сорт уңдырышлылыгы һәм авыруларга каршы тора алу сәләте белән башкаларыннан күпкә аерыла. Россиядәге климат шартларында ул бары тик ел әйләнәсе җылытыла һәм яктыртыла торган зур теплицаларда гына үстерелә ала.***

**(“Udivitelno.com”).**

*Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.*

## Дүшәмбе

### 23 октябрь

### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
